СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2021 г.Зеленодольск № 37

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы һәм 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы « Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы белән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итәргә (кушымта).
2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 7 статьясындагы 1 өлешенең 40 пункты 2021 елның 29 июнендә үз көченә керә, әмма Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы үз көченә кергәннән алданрак түгел.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

- Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 29 мартындагы 182 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы ;
- «Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 29 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы

Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2019 елның 04 мартындагы 236 номерлы карары;

- «Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 29 мартындагы 182 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» 2020 елның 02 июнендәге 292 номерлы карары.

3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны һәм аңа кушымтаны дәүләт теркәвенә алганнан соң, Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «, шулай ук әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында чыганакка сылтама белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск шәһәре Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

**Зеленодольск шәһәре Советы**
**карары белән кабул ителде**
**2021 елның 24 марты, № 37**

**Зеленодольск шәһәре Хакиме**

**__________________________М.П. Афанасьев**

Татарстан Республикасы
Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре»
муниципаль берәмлегенең

# У С Т А В Ы

Зеленодольск шәһәре
2021 ел

## I бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1 статья. Шәһәр җирлеге һәм аның статусы

1. «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенә шәһәр җирлеге статусы бирелде.

2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы - «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге (алга таба – шәһәр җирлеге).

3. «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керә.

2статья. Шәһәр җирлегенең территориаль бүленеше.

1. Шәһәр җирлеге территориясе составына Зеленодольск шәһәре керә.

2.Шәһәр җирлеге чикләре ««Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән.

3. Шәһәр җирлеге территориясе составына җирләр милек формасына һәм максатчан билгеләнешенә бәйсез рәвештә керә.

4. Шәһәр җирлеге чикләрен үзгәртү яисә үзгәртеп кору Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3 статья. Шәһәр җирлегенең рәсми символлары

1.Шәһәр җирлеге федераль законнар һәм геральдик кагыйдәләр нигезендә тарихи, мәдәни, милли һәм башка җирле традицияләрне һәм үзенчәлекләрне чагылдыра торган рәсми символларны билгеләргә хокуклы.

2. Шәһәр җирлегенең рәсми символлары, федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә, дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

3. Шәһәр җирлегенең рәсми символлары һәм әлеге символларны рәсми куллану тәртибе шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

4 статья. Шәһәр җирлегендә яшәүчеләр һәм халкы

Шәһәр җирлегендә яшәүчеләр - шәһәр җирлеге территориясендә даими яки нигездә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары (алга таба-гражданнар).

5 статья. Шәһәр җирлегендә җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга гражданнарның хокуклары

1. Шәһәр җирлегендә җирле үзидарә, әлеге Уставта каралган, Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан җирле референдумнарда, муниципаль сайлауларда катнашу юлы белән һәм турыдан-туры ризалык белдерүнең башка рәвешләрендә, шулай ук сайлау һәм җирле үзидарәнең башка органнары аша гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, дингә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына бәйсез рәвештә турыдан-туры һәм үз вәкилләре аша бертигез хокукларга ия.

3. Шәһәр җирлеге территориясендә даими яки нигездә яшәүче чит ил гражданнары җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда Россия Федерациясенең халыкара килешүләре һәм федераль законнар нигезендә хокукларга ия.

4. Шәһәр җирлегендә яшәүче һәр кеше турыдан-туры җирле үзидарә органнарына һәм аларның вазыйфаи затларына мөрәҗәгать итәргә, аларның эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга хокуклы.

5. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, әгәр дә законда башкасы каралмаган булса, һәркемгә турыдан-туры аның хокукларына һәм ирекләренә кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген, шулай ук, гражданнар тарафыннан җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка тулы һәм дөрес мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы.

6. 2009 елның 9 февралендәге «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, җирле үзидарә органнары массакүләм мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысул белән халыкка шәһәр җирлеген һәм аның аерым территорияләрен үстерүнең иң мөһим мәсьәләләре, гомуми файдаланудагы транспорт, торак-коммуналь хуҗалык эше, халыкка төрле хезмәтләр күрсәтүче социаль-мәдәни һәм башка учреждениеләр һәм хезмәтләр челтәрен үстерү, социаль ташламалар, җәмәгать тәртибен саклауның торышы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында даими рәвештә хәбәр итәләр.

6. Гражданнар, оешмалар, әгәр аларның хокуклары һәм ирекләре бозылган дип санасалар, җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судта дәгъва белдерергә хокуклы.

## 6 статья. Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасы

1. Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасына шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлегенең Ревизия комиссиясе, әлеге Устав нигезендә төзелә торган башка җирле үзидарә органнары керә.

2. Җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү шәһәр җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү юлы белән генә башкарыла.

3. Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге

башкарма-күрсәтмә органы вәкаләтләрен үтәү, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба - районның Башкарма комитетына) йөкләнә.

7 статья. Шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре

1. Шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен контрольдә тоту, җирлек бюджеты үтәлеше турындагы хисап төзү һәм раслау;

2) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

3) шәһәр җирлегенең муниципаль милкендә булган мөлкәткә идарә итү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү;

4) шәһәр чикләрендә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр эчендә, халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

5) Җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында төзелеш буенча бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма тарафыннан чаралар башкаруга муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү өчен кирәкле һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итү схемасында аның өчен билгеләнгән җылылык белән тәэмин итү объектларын реконструкцияләү һәм (яисә) модернизацияләү;

6) шәһәр җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, шәһәр җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларын куллану һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

7) шәһәр җирлегендә яшәүчеләрне һәм аз керемле гражданнарның торак урыннарына мохтаҗларны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

- күпфатирлы йортларда биналарның милекчеләренә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысуллары, капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау тәртибе турында мәгълүмат бирү;

- күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүдә кичектергесез ихтыяҗ барлыкка килгәндә җирле бюджет акчалары исәбеннән

кире кайтарып бирү һәм (яисә) кире кайтарылмый торган нигездә өстәмә ярдәм күрсәтү очракларының тәртибен һәм исемлеген раслау;

- капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау мәсьәләсен хәл итү өчен, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренә капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең гомуми җыелышын чакыру турындагы карарны кабул итү нәтиҗәләре турында хәбәр итү, әгәр мондый карар Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 6 өлеше нигезендә элегрәк кабул ителмәгән булса;

- милекчеләре капиталь ремонт фондын төзү ысулын сайлаган яки алар сайлаган ысул гамәлгә ашырылмаган йортка карата капиталь ремонт фондын формалаштыру турында карар кабул итү һәм әлеге йортта биналарның милекчеләренә кабул ителгән карар турында , шул исәптән системаны Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 7 өлеше нигезендә кулланып, хәбәр итү;

- региональ капиталь ремонт программасы нигезендә капиталь ремонт үткәрү турында карар кабул итү, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренә кабул ителгән карар турында хәбәр итү, шул исәптән, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 6 өлешендә каралган очракта, системаны кулланып;

8) шәһәр җирлеге чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

9) шәһәр җирлеге чикләрендә терроризм һәм экстремизмны профилактикалауда, шулай ук терроризм һәм экстремизм күренешләре нәтиҗәләрен минимальләштерүдә һәм (яки) бетерүдә катнашу;

10) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

11) шәһәр җирлеге чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм бетерүдә катнашу;

12) шәһәр җирлеге чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

13) халыкны элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

14) халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, шәһәр җирлеге китапханәләренең китапханә фондларының сакланышын тәэмин итү һәм комплектлау;

15) шәһәр җирлеге яшәүчеләренең ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

16) шәһәр җирлеге милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру, шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау;

17) җирле халык сәнгать иҗатын үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр җирлегендә халык сәнгать кәсепләрен саклап калуда, торгызуда һәм үстерүдә катнашу;

18) шәһәр җирлеге территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, шәһәр җирлегенең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;

19) гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына ирекле үтеп керүен тәэмин итүне дә кертеп, шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру;

20) шәһәр җирлегенең архив фондларын формалаштыру;

21) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортта ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;

22) шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук шәһәр җирлеге чикләрендә урнашкан шәһәр урманнарыннан, махсус сакланылучы табигать территорияләре урманнарыннан файдалануны, аларны саклауны, торгызуны оештыру;

23) шәһәр җирлегенең генераль планын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, шәһәр җирлегенең генераль планы нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру документларын раслау, җирлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү, төзелешкә рөхсәтләр бирү (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында, башка федераль законнарда каралган очраклардан тыш),шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә объектлар файдалануга тапшырылуга рөхсәтләр, шәһәр җирлегенең шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын раслау, җирләрне резервлау һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен шәһәр җирлеге чикләрендә җир кишәрлекләрен тартып алу, шәһәр җирлеге чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда биналарны, корылмаларны карауны гамәлгә ашыру һәм мондый тикшерүләр барышында ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында тәкъдимнәр бирү, индивидуаль торак төзелеше объектының планлаштырыла торган параметрлары яки бакча йорты билгеләнгән параметрлары турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән белешмәнамәнең туры килүе турында һәм(яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруга җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә( алга таба - планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамә), индивидуаль торак төзелеше объектының планлаштырыла торган параметрлары яки бакча йорты билгеләнгән параметрлары турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән белешмәнамәнең туры килмәве турында һәм(яки) индивидуаль торак төзелеше объектын яисә җир кишәрлегендә бакча йортын урнаштыруга җир кишәрлегендә шәхси торак төзелеше яки бакча йортын урнаштыру рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамә, индивидуаль торак

төзелеше яисә реконструкцияләнгән объектның яисә бакча йортының тиешле җирлекара территорияләрдә урнашкан җир кишәрлекләрендә индивидуаль торак төзелеше объектларын яисә бакча йортларын төзегәндә яисә реконструкциялә гәндә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе яисә туры килмәве турында хәбәрнамә җибәрү,Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларына туры китерү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җирләрдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документлары белән билгеләнгән яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләр белән (алга таба шулай ук - билгеләнгән таләпләргә туры китерү) билгеләнгән карар кабул итү, максатчан билгеләнеш буенча файдаланылмый торган яисә Россия Федерациясе законнарын бозып файдаланыла торган җир кишәрлеген тартып алу турында карар, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда,үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтүне яисә аны билгеләнгән таләпләргә туры китерүне гамәлгә ашыру;

24) шәһәр җирлеге чикләрендә адрес объектларына адреслар бирү, адресларны үзгәртү, гамәлдән чыгару, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, муниципаль районның җирле әһәмияттәге җирле юлларыннан тыш) исем бирү, планлаштыру структурасы элементларына исем бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару, дәүләт адреслы реестрында мәгълүмат урнаштыру;

25) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

26) территориаль оборона һәм гражданнар оборонасы, шәһәр җирлегенең халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

27) шәһәр җирлеге территориясендә авария-коткару хезмәтләрен һәм (яки) авария-коткару формированиеләрен төзү, карап тоту һәм аларның эшчәнлеген оештыру;

28) су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау чараларын гамәлгә ашыру;

29) шәһәр җирлеге территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук җирле әһәмияттәге махсус саклана торган табигать территорияләреннән файдалану һәм аларны саклау өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру;

30) авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыру;

31) шәһәр җирлегендә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру;

32) Россия Федерациясенең су законнары белән билгеләнгән чикләрдә, су объектлары милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, халыкка аларны куллану чикләүләре турында мәгълүмат бирү;

33) муниципаль урман контролен гамәлгә ашыру;

34) җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

18) полициянең участок вакәләтле вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә җирлекләрнең хезмәт күрсәтелә торган административ участокларында эшләү өчен бина бирү;

36) «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 31.1 һәм 31.3 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга ярдәм күрсәтү;

37) җирлекләр ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү, федераль закон нигезендә ясалма җир кишәрлекләре төзү турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү;

38) шәһәр җирлеге чикләрендә коррупциягә каршы тору чараларын гамәлгә ашыру;

39) федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу;

40) шәһәр җирлеге территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрү һәм үткәрү, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен әлеге объектларның хокукка ия булучылары турында белешмәләр җибәрү.

2. Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципальара массакүләм мәгълүмат чараларын бергә гамәлгә куючылар булып тора ала.

8 статья. Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карамаган мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары

1. Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) шәһәр җирлегенең музейларын булдыруга;

2) опека һәм попечительлек эшчәнлеген тормышка ашыруда катнашуга;

3) шәһәр җирлеге территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын гамәлгә ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруга;

4) шәһәр җирлеге территориясендә Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә ярдәм күрсәтү һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыруга;

5) шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү чараларын оештыруда һәм тормышка ашыруда катнашуга;

6) муниципаль янгын сагы булдыруга;

7) туризмны үстерү өчен шартлар тудыруга;

8) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтүгә;

9) 1995 елның 24 ноябрендәге «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларга ярдәм күрсәтүгә;

10) торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирүгә;

11) шәһәр җирлеге территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга;

12) 2016 елның 23 июнендәге «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыруга;

13) инвалидларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, җайлашу физик культурасын һәм җайлашу спортын үстерүгә ярдәм итүгә:

14) 1992 елның 7 февралендәге «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыруга;

15) полиция участок вәкаләтлесе вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирүгә;

16) алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек халәтендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыруга.

2. Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән («Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә аларга тапшырылмаган) башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашырга, әгәр дә бу катнашу федераль законнарда каралган булса, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары, җирле бюджетлар керемнәре исәбеннән, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан һәм түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керемнәреннән тыш, мәсьәләләрне хәл итәргә хокуклы.

9 нчы статья Шәһәр җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы

Шәһәр җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы федераль законнар һәм җирле үзидарә турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

10 нчы статья Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре

Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре түбәндәгечә аша гамәлгә ашырыла:

1) шәһәр җирлегенең социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән дәүләт программаларын гамәлгә ашыруда шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының катнашуы;

2) шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хакимияте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;

3) даими яисә вакытлыча координацияләү, консультатив, киңәшмә һәм башка эшче органнары булдыру;

4) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында шәһәр җирлеге Советының закон чыгару инициативасы;

5) законда билгеләнгән башка хезмәттәшлек формалары.

11 статья. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу

Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне дә кертеп, муниципаль хезмәткәр статусын билгеләү, муниципаль хезмәт үтү шартлары һәм тәртибе 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан расланган Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә һәм шәһәр җирлегенең муниципаль хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

## II бүлек. ХАЛЫК ТАРАФЫННАН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ҺӘМ ХАЛЫКНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАТНАШУЫ

12 статья. Халык тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу формалары

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасында халык тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) җирле референдум;

2) муниципаль сайлаулар;

3) депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү;

4) шәһәр җирлегенең чикләрен үзгәртү һәм үзгәртү мәсьәләләре буенча тавыш бирү;

5) гражданнар җыены;

6) гражданнарның хокукый акт чыгару инициативасы;

7) инициативалы проектлар;

8) территориаль иҗтимагый үзидарә;

9) гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар;

10) гражданнар җыелышы;

11) гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы);

12) гражданнарны сораштыру;

13) җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгате;

14) иҗтимагый (консультатив) советлар төзү;

Россия Федерациясе Конституциясенә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, башка федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формалар.

13 статья. Җирле референдум

1. Җирле референдум федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә халык тарафыннан турыдан-туры җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында үткәрелә.

2. Җирле референдум шәһәр җирлегенең бөтен территориясендә 2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

3. Җирле референдумда яшәү урыны муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары катнашырга хокуклы. Россия Федерациясе гражданнары җирле референдумда гомуми тигез һәм турыдан-туры ризалык белдерү нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән катнаша.

4. Җирле референдум үткәрү турындагы карар, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан, түбәндәге инициатива буенча кабул ителә:

1) җирле референдумда катнашу хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан күрсәтелгән инициатива буенча;

2) уставларында сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда катнашу каралган һәм федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда теркәлгән сайлау берләшмәсе, башка иҗтимагый берләшмә;

3) шәһәр җирлеге Советы һәм район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан биргә тәкъдим ителгән.

5. Әлеге статьяның 4 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар, сайлау берләшмәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр инициативасы буенча җирле референдумны билгеләү шарты булып, әлеге инициативага ярдәм итү өчен имзалар җыю тора, алар саны Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә һәм федераль закон нигезендә шәһәр җирлеге территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар саныннан биш проценттан да артмый, әмма 25 имзадан да ким була алмый.

Гражданнар, сайлау берләшмәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан тәкъдим ителгән референдум уздыру инициативасы, әлеге статьяның 4 өлешендәге 2 пунктында күрсәтелгән, Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелә.

6. Референдум үткәрү инициативасы шәһәр җирлеге Советы һәм район Башкарма комитеты җитәкчесе белән берлектә шәһәр җирлеге Советы карары һәм район Башкарма комитеты Җитәкчесе карары белән рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән инициативаны тәкъдим итү тәртибе шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

7. Шәһәр җирлеге Советы җирле референдумны, җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турындагы документлар шәһәр җирлеге Советына кергән көннән, 30 көн эчендә билгели.

8. Референдумда тавыш бирүне үткәрү датасын, билгеләнгән көнгә кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча, шәһәр җирлеге Советы карары буенча аны дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына билгеләнгән сайлауларда тавыш бирү көне яисә башка билгеләнгән референдумда тавыш бирү көне белән берләштерү максатыннан, соңрак (әмма 90 көннән дә артык түгел) вакытка күчерелергә мөмкин.

9. Тавыш бирү йомгаклары һәм җирле референдумда кабул ителгән карар рәсми басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

10. Җирле референдумда кабул ителгән карар шәһәр җирлеге территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм дәүләт хакимиятенең нинди дә булса органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан раслану кирәкми.

11. Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары җирле референдумда кабул ителгән карарның, әлеге Уставта билгеләнгән вәкаләтләрне чикләү нигезендә, үтәлешен тәэмин итәләр.

12. Җирле референдум уздыру турындагы карарга, шулай ук җирле референдумда кабул ителгән карарга карата, гражданнар, җирле үзидарә органнары, прокурор, федераль закон белән вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

13. Гражданнарның җирле референдумда катнашу хокуклары гарантияләре, шулай ук җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү тәртибе «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Җирле референдум

турында»2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына.

14 статья. Муниципаль сайлаулар

1. Шәһәр җирлегендә муниципаль сайлаулар гомуми тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә, яшерен тавыш бирү юлы белән шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлау максатыннан уздырыла.

2. Шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлау мәҗбүри, периодик рәвештә булып тора һәм әлеге Уставта билгеләнгән срокларда уздырыла.

3. Шәһәр җирлеге Советы депутаты итеп Россия Федерациясе гражданы, шулай ук федераль законнарда каралган очракларда, тавыш бирү көнендә 18 яшькә җиткән һәм сайлау хокукына ия чит ил гражданы сайлана ала.

4. Депутатларны сайлауларны билгеләү турындагы карар, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан тавыш бирү көненә кадәр 90 көннән дә иртәрәк һәм 80 көннән дә соңга калмыйча, кабул ителә. Әлеге карар кабул ителгән көннән соң, 5 көннән дә соңга калмыйча, рәсми басылып чыгарга тиеш.

Федераль законда билгеләнгән очракларда шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлау шәһәр җирлегенең Сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан билгеләнә.

5. Шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлауларын әзерләү һәм үткәрү закон һәм әлеге Устав нигезендә төзелә торган сайлау комиссияләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6. Шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлау бермандатлы сайлау округлары буенча гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

7. Бермандатлы сайлау округы буенча теркәлгән, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның иң күп тавышын җыйган кандидат сайланган дип таныла.

8.Теркәлгән кандидатлар тавышларны бертигез җыйса, алданрак теркәлгән кандидат сайланган дип санала.

9. Бермандатлы сайлау округында тавыш бирүне уздырганда, бер кандидатура буенча тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 50 проценттан да ким булмаган тавышын алган кандидат, сайланган дип санала.

10. Шәһәр җирлеге Советы депутатларын сайлау нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

15 статья. Депутатны, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү

1. Шәһәр җирлеге Советы депутаты, шул исәптән шәһәр җирлеге Башлыгы, гамәлдәге законнарда һәм әлеге Уставта билгеләнгән нигезләр һәм тәртиптә сайлаучылар тарафыннан кире чакыртып алынырга мөмкин.

2.Шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу нигезләре булып суд тәртибендә сайлаучыларны үзенә карата ышаныч, шик астына куя

торган һәм депутат вазыйфаларын яисә шәһәр җирлеге Башлыгы вазыйфаларын үтәмәгән, депутат, шәһәр җирлеге Башлыгы статусына туры килми торган гамәлләр кылу һәм Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясе законнарын һәм Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставы һәм башка муниципаль хокукый актларын бозу тора.

3. Шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү халык инициативасы буенча уздырыла.

4. Шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын тәкъдим итү һәм аны хуплап гражданнар имзаларын җыю өчен муниципаль сайлауларда катнашу хокукына ия булган , кимендә 10 кешедән торган, инициатив төркем оештырыла.

5. Инициатив төркем, инициатив төркемне теркәү турында үтенечнамә белән, шәһәр җирлегенең Сайлау комиссиясенә мөрәҗәгать итә. Инициатив төркем үтенечнамәсендә депутатны кире чакыртып алу өчен нигез булырлык законга каршы эшләнгән конкрет карары яисә гамәле (гамәл кылмавына) күрсәтмә булырга тиеш, инициатив төркемдәге һәр әгъзасының һәм шәһәр җирлеге территориясендә аның исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган көне, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе, номеры һәм бирү датасы, аны биргән органның исеме яисә коды күрсәтелеп, шулай ук яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Инициатив төркемнең үтенечнамәсе, күрсәтелгән төркемнең барлык әгъзалары тарафыннан, имзаланырга тиеш. Депутатның законга каршы эшләнгән конкрет карарын яки гамәлен (гамәл кылмавын) раслаган суд карары үтенечнамәгә беркетелгән булырга тиеш.

6. Инициатив төркемне теркәү, шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү инициативасын яклап имза җыю, җыелган имзаларны тикшерү, җирле референдум үткәрү өчен законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

7. Шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү шәһәр җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә һәм 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, җирле референдум үткәрү өчен законда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

8. Шәһәр җирлеге Сайлау комиссиясе инициатив төркеменең үтенечнамәсен караганда, шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләгәндә, шәһәр җирлеге Советының тиешле депутаты аны чакыртып алу өчен нигез итеп куелган шартлар буенча аңлатмалар бирергә, кирәкле документлар тапшырырга хокуклы. Күрсәтелгән депутат Сайлау комиссиясе, шәһәр җирлеге Советы утырышына кадәр, өч көннән дә соңга калмыйча, аларны үткәрү вакыты һәм урыны турында язмача алдан хәбәр ителергә тиеш.

9. Кире чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырганда, шәһәр җирлеге Советы депутаты кире чакыртып алу өчен нигез итеп куелган шартлар

турында сайлаучыларга аңлатмалар бирү максатларында, инициативалы төркем белән тигез нигезләрдә агитация алып бару хокукына ия.

10. Тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучыларның яртысыннан да ким булмаган өлеше кире чакыртып алу өчен тавыш бирсә, шәһәр җирлеге Советы депутаты, шул исәптән шәһәр җирлеге Башлыгы, кире чакыртып алынган дип санала.

11. Шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

12. Шәһәр җирлегенең Сайлау комиссиясе кире чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын рәсми чыгарганнан соң, 5 көн эчендә, инициатив төркемгә, шәһәр җирлеге Советына һәм шәһәр җирлеге Советының тиешле депутатына аны кире чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында җирлекнең тиешле депутатына язма рәвештә хәбәр итә.

16статья. Шәһәр җирлегенең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү

1. Чикләрне үзгәртү, шәһәр җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү , әлеге чикләрне үзгәртүгә, шәһәр җирлеген үзгәртеп коруга ризалыгын алу максатларында үткәрелә.

2. Шәһәр җирлеге чикләрен үзгәртү, шәһәр җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү шәһәр җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә. Бу очракта дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт яисә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан агитация үткәрүне тыя торган федераль закон, Татарстан Республикасы законы нигезләмәләре, шулай ук референдумда кабул ителгән карарның юридик көчләрен билгели торган нигезләмәләр кулланылмый.

3. Шәһәр җирлеге чикләрен үзгәртү, шәһәр җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, әгәр анда шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең яртысыннан күбрәге яки сайлау хокукына ия булган өлеше катнашса, сайлау уздырылган булып санала Әгәр күрсәтелгән үзгәрешләр, үзгәртеп корулар өчен шәһәр җирлегендә яисә шәһәр җирлеге өлешендә катнашкан халыкның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, шәһәр чикләрен үзгәртүгә, шәһәр чикләрен үзгәртеп коруга халыкның ризалыгы алынган дип санала.

4. Чикләрне үзгәртү, шәһәр җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

17статья. Гражданнар җыены

1. 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) күрсәтелгән торак пункт территориясен башка җирлек территориясенә кертүгә китерә торган, күрсәтелгән торак пункт составына кергән шәһәр җирлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча, торак пунктта,

2) Татарстан Республикасы Законы нигезендә шәһәр җирлеге составына керүче торак пункт территориясе өлешендә, торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында каралган, гражданнар җыены, кимендә 10 кеше яшәгән торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүчеләр төркеме инициативасы буенча, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан чакырыла ала.

Гражданнар үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча, гражданнар җыены үткәрелә торган шәһәр җирлеге составына керүче торак пункт территориясе чикләрен билгеләү критерийлары, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

3. Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены, анда сайлау хокукына ия булган торак пункт кешеләренең яртысыннан артыгы катнашканда тулы хокуклы була. Торак пунктта, бер үк вакытта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы бергә булу мөмкинлеге булмаса, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан да артмыйча үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар, тавыш бирүдә катнашуның алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.

4. Шәһәр җирлегендә яшәүчеләр гражданнар җыенын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан вакытында хәбәр ителәләр, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Зеленодольск шәһәре составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында» гы шәһәр җирлеге Советы карары белән расланган нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә, муниципаль хокукый акт проекты һәм гражданнар җыенын хәл итүгә чыгарыла торган мәсьәләләр буенча материаллар, шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең гражданнар җыенында катнашуын тәэмин итә торган башка чаралар белән алдан вакытында танышалар.

5. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан имзалана.

18статья. Гражданнарның хокукый акт чыгару инициативасы

1. Әлеге Уставта һәм шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә,сайлау хокукына ия булган гражданнарның инициатив төркеме хокукый акт чыгару инициативасы белән чыгарга мөмкин.

2. Сайлау хокукына ия булган, шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең 3 проценттан артмаган, сайлау хокукына ия булган гражданнар төркеме хокукый акт чыгару инициативасы белән чыгарга мөмкин.

Шәһәр җирлеге Советының гражданнарның хокукый акт чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибен җайга салучы норматив хокукый акты булмаган очракта, гражданнар керткән муниципаль хокукый акт проектын карап тикшерүгә һәм карауга кабул итү, 131-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Хокукый акт чыгару инициативасын гамәлгә ашыру максатларында гражданнар түбәндәгеләргә хокуклы:

яшәү (эшләү) урыны буенча гражданнар җыелышларын һәм хокукый акт чыгару инициативсыа буенча фикер алышу һәм тәкъдим итү буенча башка күмәк чараларны оештырырга һәм уздырырга;

хокукый акт чыгару инициативасын тәкъдим итүгә ярдәм итү өчен имзалар җыю буенча инициативалы төркемнәр булдыру;

шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең имзаларын җыю һәм законнарга каршы килми торган ысуллар белән хокукый акт чыгару инициативасын тәкъдим итү өчен агитация алып бару.

4. Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары гражданнарга хокукый акт чыгару инициативасын гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә тиеш.

5. Гражданнарның хокукый акт чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проекты, шәһәр җирлеге Советы, аның ачык утырышында шәһәр җирлеге Башлыгы яисә район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан тиешле актны кабул итү вәкаләтләренә кергән көннән алып, өч ай эчендә, мәҗбүри каралырга тиеш.

6. Гражданнарның хокукый акт чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын караганда, гражданнарның инициатив төркеме вәкилләренә үз позициясен белдерү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

7. Гражданнарның хокукый акт чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын карау процедурасы шәһәр җирлеге Советы Регламенты, шәһәр җирлеге Башлыгының, район Башкарма комитетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

8. Гражданнарның хокукый акт чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән нигезле карар, язмача рәсми рәвештә аны керткән гражданнарның инициатив төркеменә җиткерелергә тиеш.

19 статья. Инициативалы проектлар

1. Инициативалы проектларны тәкъдим итү, кертү, фикер алышу, карау, шулай ук аларны конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибе шәһәр җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар хисабына финанс ярдәме алу өчен тәкъдим ителә торган инициативалы проектларга карата инициативалы проектлар, инициативалы проектларны карау тәртибе, шул исәптән аларга ярдәм итүдән баш тарту өчен нигезләр, мондый инициативалы проектларны конкурс нигезендә сайлап алу тәртибе һәм критерийлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Норматив хокукый акты нигезендә билгеләнә.

20 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә

1. Шәһәр җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турыдан-туры халык тарафыннан гражданнар җыелышлары һәм конференцияләре үткәрү юлы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә органнары булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Территориаль иҗтимагый үзидарә гражданнар яшәешенең түбәндәге территорияләре чикләрендә гамәлгә ашырыла: күпфатирлы торак йорт подъезды; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайон; җирлек булмаган торак пункт; шәһәр җирлеге чикләрендә гражданнарның башка яшәү территорияләре.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре шәһәр җирлеге Советы тарафыннан әлеге территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан расланган шәһәр җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә билгеләнә.

4. Территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория, башка шундый ук территория составына керә алмый.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарә, аның уставы нигезендә, юридик зат була ала һәм коммерциячел булмаган оешманың оештыру-хокукый формасында дәүләт теркәвенә алынырга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставында түбәндәгеләр билгеләнә:

1) ул гамәлгә ашырыла торган территория;

2)территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең максатлары, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;

3)территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының вәкаләтләрен формалаштыру, туктату, хокуклары һәм бурычлары, вәкаләтләре вакыты;

4) карарлар кабул итү тәртибе;

5) мөлкәт сатып алу тәртибе, шулай ук күрсәтелгән мөлкәттән һәм финанс чараларыннан файдалану һәм алар белән эш итү тәртибе;

6) территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруны туктату тәртибе.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеге мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышлары, конференцияләре аның уставы нигезендә чакырыла.

8. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышы, әгәр анда уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүче халыкның кимендә өчтән бере катнашса, хокуклы дип санала.

Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе, әгәр анда уналты яшькә җиткән тиешле территориядә яшәүчеләрнең кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

9. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыручы гражданнар җыелышының, конференцияләренең аерым вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары структурасын билгеләү;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарын сайлау;

4) территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;

5) территориаль иҗтимагый үзидарәнең керемнәре һәм чыгымнары сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

6) территориаль иҗтимагый үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау.

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары:

1) тиешле территориядә яшәүче халык мәнфәгатьләрен чагылдыра;

2) гражданнарның җыелышларында һәм конференцияләрендә кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр;

3) территорияне карап тоту, төзекләндерү буенча хуҗалык эшчәнлеген, тиешле территориядә яшәүче гражданнарның социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән башка хуҗалык эшчәнлеген, күрсәтелгән гражданнар акчалары исәбеннән дә, шулай ук шәһәр җирлеге бюджеты акчаларын кулланып, район Башкарма комитеты белән килешү нигезендә дә тормышка ашыра алалар;

4) шәһәр җирлеге Советына, шәһәр җирлеге Башлыгына һәм район Башкарма комитетына әлеге органнар һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле муниципаль хокукый актлар проектларын кертергә хокуклы.

11. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары инициативалы проектны проект инициаторлары сыйфатында тәкъдим итә алалар.

12. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе, җирле бюджеттан кирәкле акчалар бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе әлеге Устав һәм шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

21 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыру тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатларында шәһәр җирлеге халкы, җирле үзидарә органнары инициативасы белән гражданнарның инициатив төркеме оештырыла, ул территориаль җәмәгать үзидарәсе уставы проектын эшләүне һәм территориядә яшәүче гражданнар җыелышын оештыра, аның чикләрендә әлеге территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру күздә тотыла.

2. Гражданнар җыелышы тиешле территориядә территориаль иҗтимагый үзидарә оештыру турында карар кабул итә, аның уставын кабул итә, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүгә бәйле мәсьәләләр буенча шәһәр җирлеге Советында гражданнар җыелышын тәкъдим итәргә вәкаләтле вәкилне (вәкилләрен) билгели.

3. Территориаль иҗтимагый үзидарә, шәһәр җирлеге Советы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәгән вакыттан, гамәлгә куелган дип санала.

22 статья. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү тәртибе

1. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү өчен гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) шәһәр җирлеге Башлыгына түбәндәгеләр тапшырыла:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында гражданнар җыелышының барлык вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган гариза;

2) территориаль иҗтимагый үзидарә төзү турында карар кабул ителгән, һәр вәкаләтле вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, паспорт яки граждан паспортын алыштыручы документ сериясе, номеры һәм бирү датасы, яшәү урыны күрсәтеп, гражданнар җыелышы беркетмәсе;

3) территориаль иҗтимагый үзидарә уставының ике нөсхәсе.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән документлардан тыш, башка документларны тапшыру таләп ителми. Вәкаләтле вәкилгә документлар исемлеге һәм аларны алу датасын күрсәтелгән расписка бирелә.

3. Шәһәр җирлеге Башлыгы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турындагы документлар кергән көннән алып, ике атна эчендә, аны алдан карауны һәм уставны теркәү яки теркәүдән баш тарту турында шәһәр җирлеге Советы карары проектын әзерләүне оештыра.

4. Гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкилләре территориаль иҗтимагый үзидарә уставын алдан караганда һәм киңәш бирү тавышы хокукы белән шәһәр җирлеге Советы утырышында катнашырга хокуклы.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән документларны шәһәр җирлеге Башлыгы алган көннән алып 30 көн эчендә, шәһәр җирлеге Советы территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү яисә аны теркәүдән баш тарту турында карар кабул итә. Уставны теркәүдән баш тарту нигезләнгән булырга тиеш.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүдән баш тарту өчен түбәндәге нигезләр булырга мөмкин:

1) территориаль иҗтимагый үзидарә уставы нормаларына Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, шәһәр җирлеге Уставына, башка муниципаль хокукый актларга каршы килү;

2) әлеге Уставның 20 статьясындагы 4 өлеше таләпләрен үтәмәү.

7. Территориаль иҗтимагый үзидарә оештыруның максатка ярашсызлыгын сәбәп итеп, территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәүдән баш тарту рөхсәт ителми.

8. Шәһәр җирлеге Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү мәсьәләсе буенча кабул ителгән нигезләнгән карар өч көн эчендә язма формада гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиленә (вәкаләтле вәкилләренә) җиткерелергә тиеш.

9. Шәһәр җирлеге Советы тарафыннан территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәү турында карар кабул ителгән очракта, уставның бер нөсхәсе, аны теркәү турында билге белән, гражданнар җыелышының вәкаләтле вәкиленә тапшырыла, икенче нөсхәсе шәһәр җирлеге Советында саклана.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарә уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан теркәлергә тиеш. Күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, аларны теркәгән көннән үз көченә керә.

23 статья. Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар

1. Шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышу өчен җирлектә яшәүчеләр катнашында гавами тыңлаулар үткәрергә мөмкин.

2. Гавами тыңлаулар шәһәр җирлеге халкы яки шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча уздырыла.

Халык яки шәһәр җирлеге Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар шәһәр җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә шәһәр җирлеге Башлыгы яки контракт нигезендә үз вәкаләтләрен башкаручы район Башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча- шәһәр җирлеге Башлыгы инициативасы белән .

3. Гавами тыңлауларга түбәндәгеләр чыгарылырга тиеш:

1) шәһәр җирлеге Устав проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты, Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл тасвирлау формасында, Уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатында, Уставка үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш;

2) шәһәр җирлеге бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) шәһәр җирлегенең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;

4) шәһәр җирлеген үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләр, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә шәһәр җирлеген үзгәртеп кору өчен тавыш бирү юлы белән йә гражданнар җыеннарында белдерелгән муниципаль берәмлек халкының ризалыгын алу таләп ителә торган очраклардан тыш.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү турындагы карар, тиешле орган яисә шәһәр җирлегенең вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль норматив хокукый акт проекты каралган көнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча, кабул ителергә тиеш, әгәр башка срок гамәлдәге законнарда каралмаган булса.

5. Гавами тыңлаулар үткәрү турындагы карар басылып чыккан көннән алып һәм аны үткәрү көненә кадәр шәһәр җирлегендә яшәүчеләр шәһәр җирлеге Башлыгына гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәләләр буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән муниципаль хокукый акт проектына карата гавами тыңлауларга чыгарыла торган төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы. Шәһәр җирлеге Башлыгы кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра. Күрсәтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр гавами тыңлауларда катнашучыларга җиткерелә.

6. Гавами тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре буенча, компетенциясенә гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль хокукый акт проектын кабул итү кертелгән җирле үзидарә органнары һәм шәһәр җирлегенең вазыйфаи затлары, мәҗбүри каралырга тиешле тәкъдимнәрне кабул итә.

7. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, гавами тыңлаулар уздырганнан соң, 7 көннән дә соңга калмыйча, басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

8. Гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә һәм гавами тыңлауларын үткәрү вакыты һәм урыны турында шәһәр җирлеге халкына алдан хәбәр итүне, муниципаль хокукый акт проекты белән алдан танышуны, муниципаль берәмлек халкының гавами тыңлауларында катнашуын, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен бастыруны (халыкка җиткерүне) тәэмин итә торган башка чараларны күздә тотарга тиеш.

9. Генераль план проекты, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты, территорияне планлаштыру проекты, территорияләрне ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлегеннән яки капиталь төзелеш объектыннан шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турында карар проектлары, җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, җир кишәрлекләреннән, капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән төрен үзгәртү сораулары буенча оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр җирлеге Советы тарафыннан шәһәр төзелеше

эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып раслана торган гавами тыңлаулар турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

10. Гамәлдә булган законнар һәм муниципаль норматив хокукый актлар белән гавами тыңлаулар һәм иҗтимагый фикер алышулар өчен каралган башка сроклар билгеләнмәгән очракта, әлеге статьяда күрсәтелгән сроклар кулланыла .

24 статья. Гражданнар җыелышы

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу, халыкка җирле үзидарә органнары һәм шәһәр җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, инициатив проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу өчен шәһәр җирлеге территориясе өлешендә гражданнар җыелышлары үткәрелергә мөмкин. Гражданнар җыелышлары микрорайоннар, торак массивлар, кварталлар, урамнар, торак йортлар буенча чакырыла.

2. Гражданнар җыелышы халык, шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы инициативасы белән, шулай ук территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган очракларда үткәрелә.

3. Шәһәр җирлеге Советы яисә шәһәр җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар җыелышы шәһәр җирлеге Советы яисә шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

Халык инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар җыелышы шәһәр җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә шәһәр җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Халык инициативасы буенча үткәрелә торган гражданнар җыелышы, территориаль иҗтимагый үзидарә органнарының, тиешле территориядә яшәүчеләрнең 10 проценттан ким булмаган санында һәм җыелышта катнашырга хокуклы гражданнар төркеменең, әлеге территорияләрдә урнашкан предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләренең язма тәкъдиме буенча, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.

Гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимдә аның каравына чыгарылган мәсьәләләр исемлеге, җыелыш үткәрүнең тәкъдим ителгән вакыты һәм урыны булырга тиеш. Тәкъдим вәкаләтле затлар тарафыннан, әгәр җыелыш уздыру инициативасы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать итсә, әлеге гражданнарның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, туган датасын, яшәү адресын күрсәтеп, алар тарафыннан имзаланырга тиеш.

Шәһәр җирлеге Советы гражданнарның җыелышын якындагы утырышта үткәрү турындагы тәкъдимне карый.

Шәһәр җирлеге Советы гражданнар җыелышынының максатка ярашсызлыгын сәбәп итеп, аны үткәрүдән баш тартырга хокукы юк.

5. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыру максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы белән билгеләнә.

6. Гражданнар җыелышында инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча тиешле территориядә уналты яшькә

җиткән яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициативалы проектларны кертү мәсьәләләрен карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

7. Гражданнар җыелышын үткәрү вакыты һәм урыны турында һәм фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр турында тиешле территориядә яшәүчеләр җыелыш уздырылган көнгә кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча, массакүләм мәгълүмат чараларын, почта хәбәрләрен, һәр фатирны (шәхси) тикшерү, белдерүләр һәм башка мөмкин булган чараларны кулланып хәбәр итәләр.

Гражданнар җыелышына әзерлекне һәм үткәрүне район Башкарма комитеты тәэмин итә.

8. Җыелышлар эшендә әлеге территориядә яшәүче, сайлау хокукына ия булган 18 яшькә җиткән гражданнар катнаша ала. Җыелышта катнашырга хокуклы гражданнарның гомуми саны муниципаль сайлауларны үткәргәндә файдаланыла торган Россия Федерациясе чикләрендә яшәү һәм тору урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәү исәбе мәгълүматлары нигезендә билгеләнә.

Гражданнар җыелышы җыелышта катнашырга хокуклы гражданнар саныннан кимендә өчтән бер өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

Җыелыш карарлары җыелышта катнашкан гражданнарның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

9. Гражданнар җыелышы җирле үзидарә органнарына һәм шәһәр җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләр кабул итәргә, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм шәһәр җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыелышын тәкъдим итәргә вәкаләтле затларны сайларга мөмкин.

10. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча гражданнар җыелышы территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итә.

11. Гражданнар җыелышы тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр җирле үзидарә органнары һәм шәһәр җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

12. Гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе, шулай ук гражданнар җыелышының вәкаләтләре федераль закон, әлеге Устав һәм шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый акты, территориаль иҗтимагый үзидарә Уставы белән билгеләнә.

13. Гражданнар җыелышының нәтиҗәләре аны үткәргәннән соң, бер ай эчендә, рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

25 статья. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм шәһәр җирлегендә яшәүче барлык кешеләрнең фикерен ачыклау зарурилыгы очрагында үткәрелә.

Шәһәр җирлегенең тиешле территориаль өлешләрендә яшәүчеләр арасыннан гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышларын чакыру авыр булганда, шул исәптән тиешле территориядә яшәүче һәм гражданнар җыелышында катнашу хокукына ия кешеләр саны 100 кешедән артып киткән очракта үткәрелә.

2. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыелышының вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелә. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) шәһәр җирлеге Советы яисә шәһәр җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелә. Халык инициативасы белән үткәрелә торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) шәһәр җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), әгәр анда сайланган делегатларның яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Конференция карарлары (делегатлар җыелышлары) конференциядә катнашучы делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.

5. Гражданнарны (делегатлар җыелышларын) билгеләү һәм үткәрү, делегатлар сайлау тәртибе әлеге Устав һәм шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый акты, территориаль иҗтимагый үзидарә уставы белән билгеләнә.

6. Территориаль иҗтимагый үзидарәне гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) территориаль иҗтимагый үзидарә уставында каралган тәртиптә һәм очракларда билгеләнә һәм үткәрелә.

7. Гражданнар (делегатлар җыелышлары) конференциясе нәтиҗәләре аны уздырганнан соң бер ай эчендә рәсми бастырып чыгарылырга (гавамика җиткерелергә) тиеш.

26 статья. Гражданнарны сораштыру

1. Гражданнарны сораштыру җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан кабул ителгән карарларда халыкның фикерен ачыклау һәм исәпкә алу өчен шәһәр җирлегенең бөтен территориясендә яки бер өлешендә үткәрелә.

Сораштыру нәтиҗәләре тәкъдим сыйфатында була.

2. Гражданнарны сораштыруда сайлау хокукына ия булган шәһәр җирлеге халкы катнаша ала. Инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча, гражданнар арасында үткәрелгән сораштыруда инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган шәһәр җирлеге яки аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләр катнашырга хокуклы.

3. Гражданнарны сораштыру түбәндәгеләр инициативасы буенча үткәрелә:

1) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча шәһәр җирлеге Советы яисә шәһәр җирлеге Башлыгы;

2) республика һәм республикаара әһәмияткә ия шәһәр җирлеге җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү турында карар кабул иткәндә, гражданнарның фикерен исәпкә алу өчен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары;

3) инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен, әлеге инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган, шәһәр җирлеге яки аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләр

4. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү һәм билгеләү тәртибе шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

5. Гражданнарны сораштыру билгеләү турындагы карар шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – рәсми сайт) файдаланылырга мөмкин. Шәһәр җирлеге Советының гражданнар арасында сораштыру билгеләү турындагы карарында түбәндәгеләр билгеләнә:

1) сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;

2) сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителәчәк сорауның (сорауларның) бирелеше;

3) сораштыру үткәрү методикасы;

4) сораштыру кәгазе формасы;

5)сораштыруда катнашучы шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең минималь саны.

6. Шәһәр җирлегендә яшәүчеләргә халыктан сораштыру үткәрү турында 10 көн алдан мәгълүмат җиткерелергә тиеш.

7. Гражданнарны сораштыру әзерләү һәм үткәрүгә бәйле чаралар түбәндәгечә финанслана:

1) шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары яисә шәһәр җирлеге халкы инициативасы буенча сораштыру уздырганда- шәһәр җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча сораштыру уздырганда-Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән.

8. Сораштыру нәтиҗәләре, аны үткәргәннән соң бер ай эчендә, басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Сораштыру нәтиҗәләре белән шәһәр җирлегендә яшәүче һәр кеше таныша ала. Сораштыру нәтиҗәләре шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул иткәндә мәҗбүри исәпкә алынырга тиеш.

27 статья. Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгате

1. Гражданнар шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнарына шәхси һәм күмәк мөрәҗәгатьл итәргә хокуклы.

2. Гражданнар мөрәҗәгатьләре «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ

номерлы Федераль законда, шулай ук Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда каралырга тиеш.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын бозган өчен, җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

## 28 статья. Җирлекнең иҗтимагый (консультатив) советлары

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча карарлар эшләгәндә һәм аларны тормышка ашырганда халык ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә җәмәгать контролен гамәлгә ашыру максатында, гражданнарның һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү өчен, җирлекнең Иҗтимагый советы төзелә.

2. Шәһәр җирлегенең Иҗтимагый советы шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең, иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка коммерцияле булмаган оешмаларның үз теләге белән катнашуы нигезендә формалаша.

3. Шәһәр җирлегенең Иҗтимагый советын формалаштыру тәртибе, вәкаләтләре, аның утырышларын үткәрү һәм карарлар кабул итү тәртибе, хокуклары, җирлекнең җирле үзидарә органнарының мәгълүмат бирү, консультация бирү һәм җәмәгать советы эшчәнлегенә ярдәм итүнең башка мәсьәләләренә карата бурычлары һәм җаваплылыгы, аны таркату процедурасы, шулай ук аны оештыру һәм эшчәнлекнең башка мәсьәләләре шәһәр җирлеге Советы тарафыннан расланган нигезләмә белән билгеләнә.

4. Башка Иҗтимагый (консультатив) советлар шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары каршында , аларның карарлары нигезендә барлыкка килергә мөмкин.

5. Иҗтимагый (консультатив) советларда эш иҗтимагый башлангычларда алып барыла.

## 29 статья. Шәһәр җирлеге халкы тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруның һәм аны гамәлгә ашыруда катнашуның башка формалары

1. Халыкның җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуының федераль законнар нигезендә әлеге уставта каралган формалары белән беррәттән, гражданнар җирле үзидарәне Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формаларда гамәлгә ашыруда катнашырга хокуклы.

2. Җирлек халкының җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруы һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы законлылык, ирекле принципларына нигезләнә.

Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары халыкка турыдан-туры җирле үзидарәне тормышка ашыруда һәм халыкның җирле үзидарәне тормышка ашыруда катнашуында ярдәм итәргә бурычлы.

## III бүлек. ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

30 статья . Шәһәр җирлеге Советы-шәһәр җирлеге җирле үзидарәсенең вәкиллекле органы.

1. Шәһәр җирлеге Советы-җирле үзидарәнең даими эшләүче, коллегиаль вәкиллекле органы булып тора.
2. Шәһәр җирлеге Советының рәсми исеме - «Зеленодольска шәһәр җирлеге Советы».
3. Шәһәр җирлеге Советының вәкаләтләре срогы-5 ел.
4. Шәһәр җирлеге Советы шәһәр җирлегендә яшәүчеләргә хисап тота һәм алар контролендә тора.
5. Шәһәр җирлеге Советының үз исеме белән язылган шәһәр җирлеге гербы сурәтләнгән мөһере, бланклары бар.
6. Шәһәр җирлеге Советы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары шәһәр җирлеге бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

31 статья. Шәһәр җирлеге Советы составы

1. Шәһәр җирлеге Советы бермандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайланылучы 25 депутаттан тора.
2. Шәһәр җирлеге Советы составына шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе сайланганда хокуклы була.
3. Шәһәр җирлеге Советы җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен шәһәр җирлеге Советы депутатлары арасыннан шәһәр җирлеге Советы Президиумын сайлый. Шәһәр җирлеге Советы Президиумы шәһәр җирлеге Советы органы булып тора һәм аңа хисап тота. Шәһәр җирлеге Советы Президиумы эшен формалаштыру тәртибе шәһәр җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнә.

32 статья. Шәһәр җирлеге Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты статусы.

1. Шәһәр җирлеге Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы вәкаләтләре сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш шәһәр җирлеге Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

Җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләре үз вазыйфасына кергән көннән башлана һәм яңа сайланган җирле үзидарәнең вазыйфаи заты үз вазыйфасына кергән көнне туктатыла.

2. Шәһәр җирлеге Советы депутаты даими булмаган нигездә эшли, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш,депутатлык эшчәнлеген төп эш урыны буенча эшен һәм хезмәт вазыйфаларын башкару белән бергә алып бара.

Шәһәр җирлеге Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими рәвештә гамәлгә ашыру өчен эш урынын (вазыйфасын) аена алты эш көненә саклап калу гарантияләнә.

3. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2)коммерция яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә, түбәндәге очраклардан тыш, катнашырга:

а) сәяси партиядә идарә итүдә, профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында (конференциясендә) катнашу;

б) Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә алдан хәбәрнамәсе белән коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия идарәсендә, профсоюз органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, Зеленодольск шәһәре сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешманың сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш) ;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешма идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә күрсәтү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән гайре, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлеге, Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган

булса, бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит дәүләт оешмалары, чит дәүләт гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның акчалары исәбеннән генә финанслана алмый

4) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтү советлары, чит дәүләтләрнең хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш йөртүче структур бүлекчәләре составына керергә хокуксыз.

4. Шәһәр җирлеге Советы депутаты статусы белән бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

5. Шәһәр җирлеге Советы депутатына үз вәкаләтләрен законнар, әлеге Устав, шәһәр җирлеге Советы карарлары нигезендә каршылыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин ителә.

6. Шәһәр җирлеге Советы депутаты җирлек Советы тарафыннан раслана торган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә тиеш, аларга шул исәптән депутатның түбәндәге йөкләмәләре кергән булырга тиеш:

1) җирле үзидарә органнары эшендә катнашудан тыелырга һәм депутат статусын җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә шәхсән яисә аның якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә йогынты ясау өчен файдаланмаска;

2) депутат вазыйфаларын объектив башкаруда шик тудырырлык тәртиптән тыелырга, шулай ук аның абруена яисә шәһәр җирлеге Советы абруена зыян китерә алырлык низаглы ситуацияләрдән котылырга;

3) мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү куркынычы булганда - шәхси кызыксыну депутат бурычларын объектив үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган вәзгыять туганда - бу хакта шәһәр Советына хәбәр итәргә һәм аның әлеге каршылыкны булдырмауга яисә җайга салуга юнәлдерелгән карарын үтәргә;

4) шәһәр җирлеге Советында билгеләнгән гавами чыгышлар кагыйдәләрен үтәргә;

5) депутат эшчәнлегенә бәйле булмаган максатларда конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән, депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган белешмәләрне фаш итмәскә һәм файдаланмаска;

6) физик һәм юридик затлардан депутат бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата бүләкләү, ссуда, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка акчалата бүләкләр) алмаска.

7. Шәһәр җирлеге Советы депутатлары, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзалары, шәһәр җирлеге җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда, 2012 елның

3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акча һәм (яисә) чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.

8. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Президенты карары буенча үткәрелә.

9. Әлеге статьяның 8 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон,«Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәү фактларын ачыклаганда, Татарстан Республикасы Президенты шәһәр җирлеге Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карарны кабул итәргә вәкаләтле шәһәр җирлеге Советына яисә судка башка җаваплылык чарасын куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

10. Үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес яки тулы булмаган мәгълүмат биргән шәһәр җирлеге Советы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, әгәр бу мәгълүматларны бозып күрсәтү җитди булмаса, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланылырга мөмкин:

1) кисәтү;

2) шәһәр җирлеге Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында вазыйфасыннан азат итү, аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында үз вазыйфасын биләү хокукыннан мәхрүм итү;

3)даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру хокукыннан, аның вәкаләтләре чоры беткәнче, даими нигездә вәкаләтләрен башкару хокукыннан азат итү;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында, җирле үзидарәнең сайланулы органында, аның вәкаләтләре срогы туктатылганчы вазыйфаларны биләүне тыю;

5) вәкаләтләр срогы тәмамланганчы даими нигездә вәкаләтләрен үтәүне тыю.

11. Шәһәр җирлеге Советы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән җаваплылык чараларын куллану турында карар кабул итү тәртибе, Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.

12. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы сайтында урнаштырыла һәм (яки) муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә.

13. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук ишегалды эчендәге территорияләрдә аларны үткәрү тормыш-яшәеш, транспорт яки социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшчәнлеге бозылуга китермәү, җәяүлеләрнең һәм (яки) транспорт чараларының хәрәкәтенә, я булмаса гражданнарның торак биналарга яки транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керә алуына комачаулык тудырмау шарты белән үткәрелә.Мондый очрашулар турында Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына хәбәр итү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга аларны уздыру датасы һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хокуклы.

14. Җирле үзидарә органнары депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус билгеләнгән урыннарны билгелиләр, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган урыннар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгелиләр.

15. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турындагы законнары нигезендә үткәрелә.

16. Депутатның сайлаучылар белән, җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында Россия

Федерациясе законнары белән билгеләнә торган, гавами чара формасында очрашулар оештыруына яки үткәрүенә каршылык тудырган өчен, Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылык каралган.

33 статья. Шәһәр җирлеге Советы депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәтләре

1. Шәһәр җирлеге Советы депутаты сайлаучылар, шулай ук аның сайлау округы территориясендә урнашкан предприятие, оешмалар, дәүләт һәм башка органнар коллективлары белән элемтәдә тора.

2. Шәһәр җирлеге Советы депутаты сайлаучылар алдында җаваплы һәм аларга хисап тота.

3. Шәһәр җирлеге Советы депутаты сайлаучылар алдында үз эшләре турында елга бер тапкыр хисап тота, аларга даими рәвештә шәһәр җирлеге Советы эше турында хәбәр итә, шулай ук айга кимендә бер тапкыр сайлаучыларны кабул итә.

4. Шәһәр җирлеге Советы депутаты шәһәр җирлеге халкының законлы хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнарда каралган чаралар күрергә, шул исәптән алардан кергән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карарга, аларда булган мәсьәләләрне дөрес итеп һәм үз вакытында хәл итәргә тиеш.

34 Статья. Яңа сайланган шәһәр җирлеге Советының эшен оештыру

1. Яңа чакырылыш шәһәр җирлеге Советы беренче утырышка шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе сайланганнан соң, ун көннән дә соңга калмыйча җыела. Сайлаулардан соң беренче утырыш шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан, ә ул булмаганда шәһәр җирлеге Сайлау комиссиясе тарафыннан чакырыла.

2. Сайлаулардан соң шәһәр җирлеге Советының беренче утырышын шәһәр җирлегенең яңа Башлыгы сайланганчы, яше буенча иң өлкән шәһәр җирлеге Советы депутаты ача һәм алып бара.

35 Статья. Шәһәр җирлеге Советы компетенциясе

1. Шәһәр җирлеге Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1) шәһәр җирлеге Уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;

2) шәһәр җирлеге территориясендә гомуми мәҗбүри кагыйдәләр билгеләү;

3) шәһәр җирлеге бюджетын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;

4) салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;

5) шәһәр җирлегенең социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау;

6) шәһәр җирлеге чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору турында инициативаны тәкъдим итү;

7) шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлауны билгеләү; шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлау буенча сайлау округлары схемасын раслау;

8) җирле референдумны билгеләү;

9) шәһәр җирлеге Башлыгын сайлау;

10) шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасарын сайлау;

11) Зеленодольск муниципаль районы Советына шәһәр җирлеге Советы депутатлары арасыннан шәһәр җирлеге вәкилен сайлау;

12) шәһәр җирлеге Сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү;

13) шәһәр җирлегенең чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне, шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү;

14) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру;

15) шәһәр җирлегенең муниципаль милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен, шул исәптән аны федераль законнар нигезендә хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; читләштереп калуы шәһәр җирлеге Советы тарафыннан килештерелеп яисә расланганнан соң гамәлгә ашырыла торган муниципаль мөлкәт төрләре исемлеген билгеләү;

16) муниципаль предприятиеләрне төзү, үзгәртеп кору һәм бетерү турында, шулай ук федераль законнарда каралган очраклардан тыш, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәт күрсәтүләренә тарифларны билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибен билгеләү;

17) шәһәр җирлегенең муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу тәртибен билгеләү;

18) җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;

19) җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен башкаруны контрольдә тоту;

20) шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итү;

21) шәһәр җирлеге территориясендәге урамнарга һәм торак пунктларның башка өлешләренә исем бирү һәм аларның исемнәрен үзгәртү турындагы мәсьәләләрне хәл итү;

22) гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен финанс һәм матди ресурсларның җирле резервларын булдыру һәм алардан файдалану тәртибен билгеләү;

23) муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибен билгеләү;

24) шәһәр җирлегенең Ревизия комиссиясен формалаштыру;

25) территориаль иҗтимагый үзидарә органнарына шәһәр җирлеге бюджетыннан кирәкле акчалар бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;

26) коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларны (коммуналь комплекс оешмалары – электр һәм (яки) җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләр товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифлардан тыш), коммуналь инфраструктура системасына тоташтыруга, коммуналь комплекс оешмалары тарифларына, коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәт күрсәтүләренә тарифларга өстәмәләр, кулланучылар өчен бәяләргә (тарифларга) өстәмәләр билгеләү;

27) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, шәһәр җирлегенең территориаль планлаштыру документларын, шәһәр җирлегенең шәһәр төзелеше проектлаштыруның җирле нормативларын, шәһәр җирлегеннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, башка шәһәр төзелеше документларын раслау;

28/) автоном коммерцияле булмаган оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерцияле булмаган оешмалар төзү турында карарлар кабул итү;

29) үз массакүләм мәгълүмат чараларын гамәлгә кую;

30) шәһәр җирлеге Уставын һәм шәһәр җирлеге Советы карарларын аңлату;

31) үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча шәһәр җирлеге Советы Регламентын һәм башка карарлар кабул итү;

32) шәһәр җирлеге Советы аппараты турында нигезләмәне раслау;

33) шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;

34) яшел утыртмаларны булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау;

35) муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау;

36) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирлекләрнең вәкиллекле органнары карамагына кертелгән башка вәкаләтләр, шулай ук әлеге Устав белән шәһәр җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләр;

2. Шәһәр җирлеге Советы Президиумы вәкаләтләренә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, шәһәр җирлеге Советының аерым компетенциясенә кертелмәгән мәсьәләләр керә.

3. Шәһәр җирлеге Советы яисә аерым депутатлар (депутатлар төркеме) тарафыннан, аны үтәү барышында шәһәр җирлеге бюджеты акчалары белән нинди дә булса формада булса да шәһәр җирлеге бюджеты акчалары белән идарә итү һәм (яисә) куллану рөхсәт ителми, шәһәр җирлеге Советы һәм депутатлар эшчәнлеген тәэмин итүгә юнәлдерелә торган шәһәр җирлеге бюджеты акчаларыннан тыш,

## 36 Статья. Шәһәр җирлеге Советының эш тәртибе

1. Шәһәр җирлеге Советының эш тәртибе әлеге Устав һәм шәһәр җирлеге Советының регламенты белән билгеләнә.

2. Шәһәр җирлеге Советының төп эш формасы булып аның утырышлары (сессияләре) тора, аларда шәһәр җирлеге Советы компетенциясенә караган мәсьәләләр хәл ителә.

3. Шәһәр җирлеге Советы утырышлары шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы.

4. Шәһәр җирлеге Советының чираттагы утырышлары кирәк булган саен, ләкин кимендә өч айга бер тапкыр үткәрелә. Чираттан тыш утырышлар шәһәр җирлеге Башлыгы яисә депутатлар төркеме инициативасы белән шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бер өлеше чакырыла.

5. Совет утырышлары шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан чакырыла. Шәһәр җирлеге Советы депутатлары һәм чакырылган затлар чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырыш – аны үткәрүгә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.

6. Шәһәр җирлеге Советы утырышлары ачыктан- ачык үткәрелә. Шәһәр җирлеге Советының ачык утырышларында теләсә кайсы граждан катнаша ала.

7. Шәһәр җирлеге Советының һәр утырышында беркетмә алып барыла. Утырыш беркетмәсенә утырышны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында белешмәләр кертелә, карала торган барлык мәсьәләләр санап үтелә һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен күрсәтеп, барлык кабул ителгән карарлар теркәлә.Шәһәр җирлеге Советы утырышы беркетмәсенә шәһәр җирлеге Башлыгы кул куйганнан соң, аның белән шәһәр җирлегендә яшәүче һәр кеше таныша ала.

8. Шәһәр җирлеге Советы утырышларында һәр депутат бер тавышка ия. Шәһәр җирлеге Советы депутаты үзенең тавыш бирү хокукын шәхсән үзе гамәлгә ашыра. Шәһәр җирлеге Советы утырышларында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемле) һәм яшерен булырга мөмкин. Тавыш бирүнең һәр төрен куллану очраклары әлеге Устав, шәһәр җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнә.

9. Шәһәр җирлеге Башлыгы тавышы шәһәр җирлеге Советы карарларын кабул иткәндә шәһәр җирлеге Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.

10. Россия Федерациясе, йә Татарстан Республикасы территориясендә, йә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә, йә Зеленодольск шәһәре территориясендә югары әзерлек, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яисә хәрби хәл кертелгән чорда шәһәр җирлеге Советы рәисе карары буенча район Советы утырышларын уздыруның аерым тәртибе билгеләнергә мөмкин.

11. Шәһәр җирлеге Советы утырышларының аерым тәртибе гамәлдә булган чорда, утырышлар видеоконференцэлемтә рәвешендә, мәгълүмат - телекоммуникацион элемтә челтәрләреннән файдаланып (алга таба - дистанцион формада) үткәрелергә мөмкин.

12. Шәһәр җирлеге Советы утырышларын дистанцион формада үткәрү турындагы карар, шәһәр җирлеге Башлыгы-шәһәр җирлеге Советы Рәисе тарафыннан кабул ителә.

Шәһәр җирлеге советы утырышын үткәрү турындагы карарда

дистанцион формада әлеге утырышка чакырылган затлар исемлеге билгеләнә.

Шәһәр җирлеге Советы утырышында дистанцион формада катнашу мөмкинлеге Башкарма комитет җитәкчесенә, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре прокурорына мәҗбүри тәртиптә тәэмин ителә.

13. Шәһәр җирлеге советы утырышын үткәрү турындагы мәгълүмат дистанцион рәвештә шәһәр җирлеге Советы депутатларына (чакырылган кешеләргә) җибәрелә һәм рәсми сайтка урнаштырыла.

14. Шәһәр җирлеге Советы утырышында шәһәр җирлеге Советының күрсәтелгән органнары әгъзалары булмаган затларның дистанцион рәвештә катнашуы, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм муниципаль норматив-хокукый актларның таләпләрен исәпкә алып, шәһәр җирлеге Башлыгы карары буенча гамәлгә ашырыла.

15. Шәһәр җирлеге Советы утырышында карарлар дистанцион формада ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сорауларга язылу, чыгышларга язылу утырышта катнашучы депутатларны сораштыру юлы белән үткәрелә (кулларны күтәрү, шәһәр җирлеге Советы депутатларының дистанцион формада утырыш башында билгеләнгән башка ысуллар).

16. Шәһәр җирлеге Советы утырышын дистанцион формада шәһәр җирлеге Башлыгы карары белән рәсми сайтта трансляцияләү мөмкин.

17. Шәһәр җирлеге Советы утырышы үткәрелгәндә, дистанцион формада утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә, утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

18. Шәһәр җирлеге Советы утырышы беркетмәсенә утырышны үткәргәндә кулланыла торган программа чаралары, утырышны башлау һәм тәмамлау вакыты өстәмә рәвештә кертелә. Беркетмәгә утырышның аудио - һәм видеоязмасы теркәлә.

19. Шәһәр җирлеге Советы Президиумы эшен оештыру шәһәр җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнә.

37 Статья. Шәһәр җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру

1. Шәһәр җирлеге Советы эшчәнлеген оештыруны шәһәр җирлеге Башлыгы башкара.

2. Шәһәр җирлеге Советы Регламенты нигезендә шәһәр җирлеге Советы компетенциясенә караган сорауларны алдан карау һәм әзерләү өчен, депутатлар арасыннан, шәһәр җирлеге Башлыгы һәм аның урынбасарыннан тыш, даими яки вакытлы комиссияләр төзелә (яисә) шәһәр җирлеге Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча әлеге күрсәтелгән сорауларны әзерләү өчен җаваплы депутатлар билгеләнә ала. Депутат ике даими комиссиядә дә эшләргә хокуклы.

3. Муниципаль программаларны, шәһәр җирлеге Советы карарлары проектларын әзерләү, шәһәр җирлеге карамагына кертелгән иң мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен, шәһәр җирлеге Советы каршында, аның карары буенча депутатлар, район Башкарма комитеты, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар һәм предприятиеләр вәкилләре, белгечләр,

экспертлар һәм шәһәр җирлеге халкы составында эшче, эксперт һәм башка киңәшмә төркемнәре төзелергә мөмкин.

38 статья. Шәһәр җирлеге Советы тарафыннан контроль функцияләр башкару

1. Шәһәр җирлеге Советы шәһәр җирлеге территориясендә әлеге Уставның шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә торган норматив актларның үтәлешен, шәһәр җирлеге бюджетының үтәлешен, бюджеттан тыш фондлар акчаларын куллануны, шәһәр җирлеген үстерү программаларын куллануны, район Башкарма комитеты һәм аның Җитәкчесе эшчәнлеген контрольдә тота.

2. Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан закон, әлеге Устав һәм башка муниципаль хокукый актларны бозу фактлары ачыкланган очракта, шәһәр җирлеге Советы карары белән депутатлар арасыннан әлеге фактларны тикшерү өчен вакытлыча контроль комиссияләре төзелергә мөмкин.

3. Законнар нигезендә шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыклары шәһәр җирлеге бюджеты акчаларын максатчан файдалану, муниципаль милекне файдалануның нәтиҗәлелеге, шулай ук район Башкарма комитетының финанс-хуҗалык эшчәнлегенең башка мәсьәләләре буенча тикшерүләр (ревизияләр) үткәрергә мөмкин. Тикшерүләр (ревизияләр) үткәрүгә бәйсез аудиторлар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре билгеләнгән тәртиптә җәлеп ителергә мөмкин.

4. Район Башкарма комитеты, аның Җитәкчесе, предприятие, учреждениеләр, оешмалар, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, законда башкача билгеләнмәгәндә, шәһәр җирлеге Советы, аның контроль комиссияләре, шәһәр җирлеге Советы депутаты мөрәҗәгате буенча соратып алына торган мәгълүматны шәһәр җирлеге Советы карамагына тапшырырга, ә муниципаль хокукый актларның законнарын бозган очракта, хокук бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

5. Шәһәр җирлеге Советы җирлек Башлыгының эшчәнлек нәтиҗәләре турында еллык хисапларын, җирлек Башкарма комитетының һәм җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы башка органнарның эшчәнлеген, шул исәптән шәһәр җирлеге Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында да тыңлый.

6. Шәһәр җирлеге Советы, контроль функцияләр башкарып, район Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкарма-боеру эшчәнлегенә катнашырга хокукы юк.

39 статья. Муниципаль район Советына шәһәр җирлеге вәкилен сайлау

1. Шәһәр җирлеге вәкиле Зеленодольск муниципаль районы Советына шәһәр җирлеге Советы депутатлары арасыннан яшерен яисә ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.

2. Шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан яртысыннан артыгы аның өчен тавыш биргән кандидат сайланган дип санала.

40 статья. Шәһәр җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Шәһәр җирлеге Советының вәкаләтләре 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 статьясында каралган тәртиптә һәм нигезләрдә вакытыннан алда туктатылырга мөмкин. Шәһәр җирлеге Советы вәкаләтләре шулай ук түбәндәге очракта туктала:

1) шәһәр җирлеге Советы тарафыннан үз-үзен таркату турында карар кабул итүе. Шул ук вакытта үз-үзен таркату турында карар шәһәр җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә кабул ителә;

2) шәһәр җирлеге Советы депутатларының әлеге составының законсызлыгы турында Татарстан Республикасы Югары суды карарының үз көченә керүе, шул исәптән депутатларның үз вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә;

3) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3, 5, 7, 7.2 өлешләре нигезендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль берәмлекне үзгәртеп корган очракта, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта;

4) шәһәр җирлеге тарафыннан аның шәһәр округы белән берләшүенә бәйле рәвештә муниципаль берәмлек статусын югалту;

5) шәһәр җирлегенең шәһәр округы белән бергә берләшкәндә яисә шәһәр җирлеге белән шәһәр округы чикләренең үзгәрүе нәтиҗәсендә килеп чыкканда сайлаучылар саны 25 процентттан арту;

6) халыкның турыдан-туры ризалыгын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль хокукый актны бастырып чыгару срогын бозу.

2. Шәһәр җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату аның депутатларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга китерә.

3. Шәһәр җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, вакытыннан алда сайлаулар федераль закон белән билгеләнгән срокларда үткәрелә.

41 статья. Шәһәр җирлеге Советының үз-үзен таркату турында карар кабул итү тәртибе

1. Шәһәр җирлеге Советының үз-үзен таркату турындагы карар шәһәр җирлеге Башлыгы яисә шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә яртысыннан торган депутатлар төркеме инициативасы

белән кабул ителергә мөмкин.

2. Үз-үзен таркату турында карар кабул итү инициативасы түбәндәге очракта тәкъдим ителми:

1) шәһәр җирлеге Советы сайланганнан соң беренче елында;

2) шәһәр җирлеге бюджетын кабул итү һәм аның үтәлеше турында хисапны раслау чорында;

3) шәһәр җирлеге Башлыгын кире чакыртып алу турында тавыш бирү уздыру чорында йә аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда.

3. Шәһәр җирлеге Советының үз-үзен таркату турындагы язма тәкъдимендә үз-үзен таркату мотивлары булырга тиеш, шулай ук аңа үз-үзен таркату сәбәпләрен нигезли торган башка материаллар кушылырга мөмкин.

4. Депутатлар арасыннан үз-үзен таркату мәсьәләсен алдан карау өчен шәһәр җирлеге Советы карары белән комиссия төзелә. Шәһәр җирлеге Советы яисә шәһәр җирлеге Башлыгы карары белән шәһәр җирлеге Советының үз-үзен таркату турындагы мәсьәлә халык алдында тыңлауларга чыгарылырга мөмкин.

5. Шәһәр җирлеге Советының үз-үзен таркату турындагы мәсьәләне карау дәвамлылыгы шәһәр җирлеге Советы депутатлары һәм шәһәр җирлеге халкы тарафыннан үз-үзен таркату инициативасының барлык шартлары һәм нигезләмәләре буенча һәрьяклы һәм объектив фикер алышу мөмкинлеген гарантияләргә тиеш. Үз-үзеңне таркату турында карар үз-үзеңне таркату турындагы инициативаны тәкъдим иткән көннән ике ай узгач кабул ителергә мөмкин.

6. Шәһәр җирлеге Советының үзен таркату турында карары шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән саныннан өчтән икесенең тавышы белән яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

7. Шәһәр җирлеге Советы үз-үзен таркату турындагы тәкъдимен кире кагылган очракта, үз-үзен таркату турында кабат инициатива үз-үзен таркату турындагы мәсьәлә буенча тавыш биргән көннән бер елдан да соңга калмыйча тәкъдим ителергә мөмкин.

42 статья. Шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракта туктатыла:

1) үлгәндә;

2) үз теләге белән отставкага чыкканда;

3) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылганда;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылганда яисә вафат булган дип игълан ителгәндә;

5) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә кергәндә;

6) Россия Федерациясе чикләреннән тыш даими яшәү урынына күчкәндә;

7) Россия Федерациясе гражданлыгы бетерелгәндә, чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану мөмкинлеге биргән Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы гамәлдән чыкканда, Россия гражданына җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук биргән Россия Федерациясе белән халыкара килешүдә тормаган чит ил гражданлыгын яисә яшәп тору кәгазен алганда, яисә Россия гражданына җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук биргән Россия Федерациясе белән халыкара килешүдә тормаган чит ил территориясендә даими яшәү хокукын бирүче башка документ алганда;

8) сайлаучылар тарафыннан кире чакыртып алганда;

9) шәһәр җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатылганда;

10) хәрби хезмәткә чакырылганда яки аны алыштыручы альтернатив гражданлык хезмәтенә җибәрелгәндә;

11) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.

2. Шәһәр җирлеге Советының шәһәр җирлеге депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карары, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән алып, 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, ә бу нигез шәһәр җирлеге Советы сессияләре арасында барлыкка килгән очракта, - мондый нигез барлыкка килгән көннән соң өч айдан да соңга калмыйча.

Татарстан Республикасы Президентының шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгән көн- шәһәр җирлеге Советына әлеге гаризаның кергән көне тора.

3. Шәһәр җирлеге Советының әлеге статьяның 1 өлешендәге 1-7, 10 һәм 11 пунктларында күрсәтелгән очракларда шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен туктату турында карарында шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен туктату көне билгеләнә.

4. Шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре, әлеге статьяның 1 өлешендәге 8 пунктында каралган очракта, шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгарган көннән туктатыла.

5. Шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре әлеге статьяның 1 өлешендәге 9 пунктында каралган очракта, шәһәр җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

6. Шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, депутатның өстәмә сайлаулар федераль закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә билгеләнә.

7. Шәһәр җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

## IV бүлек. ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

43 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгы-шәһәр җирлегенең югары вазыйфаи заты

1. Шәһәр җирлеге Башлыгы шәһәр җирлегенең иң югары вазыйфаи заты булып тора.
2. Шәһәр җирлеге Башлыгы шәһәр җирлеге Советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе булып тора.
3. Шәһәр җирлеге Башлыгының рәсми исеме – «Зеленодольск шәһәре Хакиме».
4. Шәһәр җирлеге Башлыгы вазыйфасы буенча Зеленодольск муниципаль районы Советы депутаты булып тора.

44 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгын сайлау тәртибе

1. Шәһәр җирлеге Башлыгы яңа сайланган шәһәр җирлеге Советының беренче сессиясендә, шәһәр җирлеге Советы вәкаләтләре вакытына шәһәр җирлеге Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана. Шәһәр җирлеге Башлыгын сайлау шәһәр җирлеге Советы депутатлары тарафыннан тәкъдим ителә торган кандидатлар арасыннан, шул исәптән шәһәр җирлеге халкы, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.
2. Шәһәр җирлеге Советы депутаты, әгәр аны сайлау өчен шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан артыгы тавыш бирсә, шәһәр җирлеге Башлыгы итеп сайланган дип санала.
3. Сайланганнан соң шәһәр җирлеге Башлыгы түбәндәге ант бирә:
«Зеленодольск шәһәре Хакименең үземә йөкләнгән югары вазыйфаларын башкарганда Россия Федерациясе Конституциясен һәм законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын, «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставын үтәргә, «Зеленодольск шәһәре»муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең тормыш дәрәҗәсен тәэмин итү өчен, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өчен бөтен көчемне һәм белемнәремне куярга».

45 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгы статусы

1. Шәһәр җирлеге Башлыгы даими нигездә эшли.
2. Шәһәр җирлеге Башлыгы Зеленодольск муниципаль районы Советында даими нигездә биләп торучы вазыйфага сайланган очракта, ул шәһәр җирлеге Башлыгы вәкаләтләрен даими булмаган нигездә башкара.
3. Шәһәр җирлеге Башлыгы 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәргә тиеш. Шәһәр җирлеге Башлыгының вәкаләтләре 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләгән затларның һәм башка

затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, вакытыннан алда туктатыла.

4. Шәһәр җирлеге Башлыгы үз эшчәнлегендә шәһәр җирлеге халкына һәм шәһәр җирлеге Советына федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә контрольдә тора һәм хисап тота.

5. Шәһәр җирлеге Башлыгы шәһәр җирлеге Советына ел саен үз эшчәнлекләренең нәтиҗәләре турында хисап тота.

46 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгы вәкаләтләре

Шәһәр җирлеге Башлыгы:

1) шәһәр җирлеген башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә, ышанычнамәсез шәһәр җирлеге исеменнән эш итә;

2) шәһәр җирлеге Советы эшен оештыра, шәһәр җирлеге Советы һәм шәһәр җирлеге Советы Президиумы утырышларын чакыра һәм аларга рәислек итә;

3) шәһәр җирлеге Советының чираттан тыш утырышы чакыруын таләп итәргә хокуклы;

4) әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән хокукый актларга имза сала һәм халыкка җиткерә;

5) үз вәкаләтләре кысаларында шәһәр җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча хокукый актлар чыгара;

6) шәһәр җирлеге Советы эшендә хәбәрдарлыкны һәм җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны тәэмин итү буенча чаралар күрә;

7) гражданнарны кабул итүне, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;

8) шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Советы Президиумы утырышлары беркетмәләренә кул куя;

9) шәһәр җирлеге Советы аппараты эше белән җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

10) шәһәр җирлеге Советының контроль вәкаләтләрен тормышка ашыруны координацияли;

11) шәһәр җирлеге Советын карап тоту һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү өчен шәһәр җирлеге бюджетында каралган чыгымнар буенча акча бүлүче булып тора;

12) гражданнарның турыдан-туры ризалыгын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны тормышка ашыру буенча шәһәр җирлеге Советының хокукый актын закон һәм әлеге Устав нигезендә кабул итүне оештыра;

13) шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, башка федераль органнар, шәһәр җирлеге территориясендә эш итүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән тиешле үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

14) шәһәр җирлеге исеменнән дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән икътисадый һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә хезмәттәшлек турында шартнамәләр һәм килешүләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итү һәм гамәлләрне координацияләү турында шартнамәләр һәм килешүләр төзи;

15) финанс органы турындагы нигезләмә нигезендә бюджетның агымдагы үтәлешен контрольдә тота.

16) җирле үзидарә органнары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

17) муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру хакында карар кабул итә, әгәр гавами партнер муниципаль берәмлек булса йә муниципаль берәмлек катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылса (Россия Федерациясе , Россия Федерациясе субъекты катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган очрактан тыш), шулай ук 2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 224-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясенең башка федераль законнары һәм норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары, шәһәр җирлеге Уставы һәм шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый актлары белән каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

17.1) 2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлешендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы билгели;

17.2) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына, проектның нәтиҗәлелеген бәяләү уздыру һәм аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен, 2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 224-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 - 5 өлешләре нигезендә, муниципаль-хосусый партнерлык проектын җибәрә;

18) федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән муниципаль берәмлекләр Башлыклары карамагына кертелгән башка вәкаләтләрне, шулай ук әлеге Устав, шәһәр җирлеге Советы карарлары белән шәһәр җирлеге Башлыгы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

47 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары

1. Шәһәр җирлеге Башлыгы тәкъдиме белән шәһәр җирлеге Советы тарафыннан депутатлар арасыннан шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары сайлана.

2. Шәһәр җирлеге Советы депутаты, әгәр аны сайлау өчен шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан яртысыннан артыграгы тавыш бирсә, шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары дип сайланган була.

3. Шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары вазыйфаларны шәһәр җирлеге Советы Регламентында билгеләнгән бурычларны бүлү нигезендә башкара, җирлек Башлыгы йөкләмәсен үти, ә вакытлыча (авыру яки отпускка китү сәбәпле) яки үз вазыйфалары башкара алмаган очракта, яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, җирлек Башлыгы вазыйфаларын башкара.

4. Шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасарының рәсми исеме – «Зеленодольск шәһәре Хакиме урынбасары».

5. Шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары үз вәкаләтләрен бушатылган яки бушатылмаган нигездә башкара. Шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасарының эш шартлары шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

6. Шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары вәкаләтләре әлеге Уставның 42 статьясындагы 1 өлешендә каралган нигезләр буенча вакытыннан алда туктатыла.

Шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасарының вәкаләтләре 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

7. Җирлек Башлыгы урынбасары, җирлек Советы карары белән, җирлек Башлыгы инициативасы белән кабул ителгән яки җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бер өлеше булган депутатлар төркеме таләбе буенча, теләсә кайсы вакытта да вазифасыннан кире чакыртып алынырга мөмкин. Җирлек Башлыгы урынбасарын кире чакыртып алу турындагы карар җирлек Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

48 статья. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга салына торган чикләүләр һәм вазыйфалар

1. Шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары вазыйфаларын биләүче затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре

турында белешмәләр тапшыралар.

2. Шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары вазыйфаларын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районы сайтында урнаштырыла һәм (яки) массакүләм мәгълүмат чараларын муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгару өчен бирелә.

3. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының югары вазыйфаи заты (Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) карары буенча гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге статьяның 3 өлеше нигезендә гамәлгә ашырылган тикшерү нәтиҗәсендә шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары вазыйфаларын биләүче зат тарафыннан, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Шәһәр җирлеге Башлыгының вәкаләтләре 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль законда, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыймматле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы Президенты шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле шәһәр җирлеге Советына башка дисциплинар чара куллану турында гариза белән яисә судка мөрәҗәгать итә.

49 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату

1. Шәһәр җирлеге Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракта туктатыла:

1) үлгәндә;

2) үз теләге белән отставкага чыкканда;

3) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74.1 статьясы нигезендә отставкага җибәргәндә;

4) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында » 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфадан читләшкәндә;

5) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылганда;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылганда яисә вафат булган дип игълан ителгәндә;

7) аңа карата судның гаепләү карары законлы көченә кергәндә;

8) Россия Федерациясе чикләреннән тыш даими яшәү урынына күчкәндә;

9) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда, чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнаша торган чит дәүләт гражданлыгы туктатылганда, дәүләт гражданлыгын алганда яки чит дәүләт гражданлыгына ия Россия Федерациясе гражданына җирле үзидарә органнарына сайланырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашмый торган чит дәүләт территориясендә Россия Федерациясе гражданының яшәүгә рөхсәт яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алганда;

10) сайлаучылар тарафыннан кире чакыртып алганда;

11) сәламәтлеге торышы буенча суд тәртибендә шәһәр җирлеге Башлыгының вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга сәләтсез булуында билгеләнгәндә;

12) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 3, 3.1-1, 3.2, 3.3, 4 - 6.2, 7 - 7.2 өлешләре нигезендә, шәһәр җирлеген үзгәртеп корганда, шулай ук шәһәр җирлеге бетерелгән очракта;

13) шәһәр җирлеге тарафыннан аның шәһәр округы белән берләшүенә бәйле рәвештә муниципаль берәмлек статусы югалган очракта;

14) шәһәр җирлеге чикләрен үзгәртү яки шәһәр җирлегенең шәһәр округы белән берләшүе нәтиҗәсендә шәһәр җирлектә сайлаучылар санының 25 процентган артып киткәндә;

2. Шәһәр җирлеге Башлыгының вәкаләтләре шулай ук, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачарга һәм саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»» 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны йөкләмәләрне үтәмәүгә бәйле рәвештә дә вакытыннан алда туктатыла.

3. Шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы мәсьәләне караганда, шәһәр җирлеге белән вәкаләт бирелгән утырыш, шәһәр җирлеге Советы депутаты рәислегендә уза.

4. Шәһәр җирлеге Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яисә суд карары буенча аны сак астына алу яки вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары башкара.

5. Шәһәр җирлеге Башлыгының әлеге статьяның 1 өлешендәге 1-11 пунктларында һәм 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләрдә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, шәһәр җирлегенең яңа Башлыгын сайлау шәһәр җирлеге Советының якындагы утырышында гамәлгә ашырыла.

6. Шәһәр җирлеге Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан, үз составыннан яисә конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан сайлап алына торган шәһәр җирлеге Башлыгын сайлау, вәкаләтләр туктатылган көннән соң алты айдан да соңга калмыйча башкарыла.

Шул ук вакытта, әгәр шәһәр җирлеге Советының вәкаләтләре вакыты чыгарга алты айдан да кимрәк вакыт калса, шәһәр җирлеге Башлыгын шәһәр җирлеге Советы составыннан сайлау яңа сайланган шәһәр җирлеге Советының беренче утырышында, ә конкурс нәтиҗәләре буенча, конкурс комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан, шәһәр җирлеге Башлыгын сайлау хокуклы составтында, шәһәр җирлеге Советы сайланганнан соң өч ай эчендә башкарыла.

7. Вәкаләтләре шәһәр җирлеге Башлыгы вазыйфасыннан читләштерү турында Татарстан Республикасы Президентының хокукый акты нигезендә йә шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турында шәһәр җирлеге Советы карары нигезендә вакытыннан алда туктатылган шәһәр җирлеге Башлыгы әлеге хокукый актка яисә суд тәртибендә карарга шикаять бирсә, шәһәр җирлеге Советы үз составыннан яисә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясендә тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан шәһәр җирлеге Башлыгын сайлау турында карар кабул итү хокукына ия түгел.

50 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгының отставкага китүе

1. Шәһәр җирлеге Советы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрергә хокуклы.

2. Шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

1) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 75 статьясындагы 1 өлешенең 2 һәм 3 пунктларында каралган нәтиҗәләргә китерә торган (йогынты ясаган) шәһәр җирлеге Башлыгы карарлары, гамәлләре (гамәл кылмавы);

2) 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда, әлеге Уставта каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча өч һәм аннан да күбрәк ай дәвамында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вазыйфаларны үтәмәү, һәм (яисә) җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча вазыйфаларны үтәмәү;

3) шәһәр җирлеге Башлыгы эшчәнлегенә шәһәр җирлеге Советы тарафыннан, шәһәр җирлеге Советы алдында ике тапкыр рәттән ел саен бирелә торган хисап нәтиҗәләре буенча, канәгатьләнерлек булмаган бәя бирү;

4) 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ санлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 230-ФЗ санлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм булдыруны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәүгә, йөкләмәләрне башкармау;

5) шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлегенең башка органнары һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары һәм ведомство карамагындагы оешмалар тарафыннан расасына, милләтенә, теленә, диненә һәм башка шартларга карап кеше һәм граждан хокуклары һәм ирекләре тигезлегенең дәүләт гарантияләрен массакүләм бозуга китерү, раса, милли, тел яки дини билгеләре буенча хокукларны чикләү һәм дискриминацияләү, әгәр дә бу милләтара һәм динара татулыкны бозуга китереп чыгарса, милләтара (этникара) һәм конфессияара конфликтлар килеп чыгуга китерсә.

3. Шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турында шәһәр җирлеге Советы депутатларының, шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бере тәкъдим ителгән инициативасы, шәһәр җирлеге Советына кертелә торган мөрәҗәгать рәвешендә рәсмиләштерелә. Күрсәтелгән мөрәҗәгать шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турында шәһәр җирлеге Советы карары проекты белән бергә кертелә. Әлеге инициативаны тәкъдим итү турында шәһәр җирлеге Башлыгы һәм Татарстан Республикасы Президенты, шәһәр җирлеге Советына күрсәтелгән мөрәҗәгать кертелгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, хәбәр ителә.

4. Шәһәр җирлеге Советы депутатларының шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасын карау, Татарстан Республикасы Президенты фикерен исәпкә алып, гамәлгә ашырыла.

5. 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль

законның 75 статьясындагы 1 өлешенең 2 һәм 3 пунктларында каралган, әгәр шәһәр җирлеге Советы депутатларының шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага чыгару турындагы инициативасын караган очракта, җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә һәм (яисә) хәл ителеше нәтиҗәләренә китергән шәһәр җирлеге Башлыгының гамәлләренә (гамәл кылмавына) кагылышлы мәсьәләләрне карау күздә тотылса, шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турында карар бары тик Татарстан Республикасы Президенты ризалыгы белән генә кабул ителергә мөмкин.

6. Татарстан Республикасы Президентының шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасы мөрәҗәгать рәвешендә рәсмиләштерелә, ул шәһәр җирлеге Советына шәһәр җирлеге Советының тиешле карары проекты белән бергә кертелә. Әлеге инициативаны тәкъдим итү турында шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Советына күрсәтелгән мөрәҗәгать кертелгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, хәбәр ителә.

7. Шәһәр җирлеге Советы депутатлары яисә Татарстан Республикасы Президентының шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасын карау, тиешле мөрәҗәгать кергән көннән алып бер ай эчендә, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Шәһәр җирлеге Советының шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы карары, әгәр аның өчен шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

9. Шәһәр җирлеге Советының шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы карары шәһәр җирлеге Советы утырышында рәислек итүче депутат тарафыннан имзалана.

10. Шәһәр җирлеге Советы тарафыннан, шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турында карар каралганда һәм кабул ителгәндә, түбәндәгеләр тәэмин ителергә тиеш:

1) тиешле утырышны уздыру датасы һәм урыны турында аларга алдан хәбәрнамә җибәрү, шулай ук шәһәр җирлеге Советы депутатлары яисә Татарстан Республикасы Президенты мөрәҗәгате һәм аны отставкага җибәрү турында шәһәр җирлеге Советы карары проекты белән танышу;

2) аңа, шәһәр җирлеге Советы депутатларына отставкага җибәрү өчен нигез буларак куела торган хәлләргә карата ,аңлатма бирү мөмкинлеге бирү.

11. Шәһәр җирлеге Уставы нигезендә шәһәр җирлеге Башлыгы шәһәр җирлеге Советы составына керә һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкара икән, шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы карар шәһәр җирлеге Советы утырышында рәислек итүче депутат тарафыннан имзалана.

12. Шәһәр җирлеге Советы составына керүче һәм аның рәисе вәкаләтләрен башкаручы шәһәр җирлеге Башлыгы, аны отставкага чыгару турындагы мәсьәлә карала торган шәһәр җирлеге Советы утырышында катнашкан очракта, әлеге утырыш, шәһәр җирлеге Советы белән вәкаләтле, шәһәр җирлеге Советы депутаты рәислегендә уза.

13. Шәһәр җирлеге Башлыгы, аны отставкага җибәрү турында шәһәр җирлеге Советы карары белән килешмәгән очракта, ул үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

14. Шәһәр җирлеге Советының шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы карары, кабул ителгән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча, рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Әгәр шәһәр җирлеге Башлыгы, аны отставкага җибәрү мәсьәләсе буенча үзенең аерым фикерен язмача белдерсә, ул шәһәр җирлеге Советының күрсәтелгән карары белән бер үк вакытта басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

15. Әгәр шәһәр җирлеге Советы депутатлары яисә Татарстан Республикасы Президентының шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы инициативасы шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кире кагылган булса, шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турындагы мәсьәлә, шәһәр җирлеге Советы утырышын үткәргән көннән ике айдан да соңга калмыйча, шәһәр җирлеге Советына кабат карауга чыгарылырга мөмкин.

16. Шәһәр җирлеге Башлыгына карата шәһәр җирлеге Советы тарафыннан аны отставкага җибәрү турында карар кабул ителгәндә, ул күрсәтелгән карарга шикаять белдерү турында гариза белән судка, мондый карар рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн эчендә, мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Суд, гариза биргән көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча, гаризаны карарга һәм карар кабул итәргә тиеш.

## V бүлек. ЫШАНЫЧ ЮГАЛТУ БӘЙЛЕ РӘВЕШТӘ, ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ БИЛӘҮЧЕ ЗАТЛАРНЫ ЭШТӘН ЧЫГАРЫЛУ (ВАЗЫЙФАДАН АЗАТ ИТҮ)

### 51 статья. Ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны эштән чыгару (вазыйфадан азат итү)

1. Федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган тәртиптә муниципаль вазыйфа биләүче зат, ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, түбәндәге очракта эштән азат чыгарылырга (вазыйфадан азат ителергә) тиеш:

1) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча, тарафдары булып торган, зат тарафыннан чаралар күрмәү;

2) зат тарафыннан үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәү яисә, әгәр федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса, белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр бирү;

3) затның, Федераль законда билгеләнгән очраклардан тыш, коммерция оешмасы белән идарә итү органы эшчәнлегендә түләүле нигездә катнашуы;

4) зат тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

5) затның Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительлек яисә күзәтү советлары, чит дәүләтләрнең хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш йөртүче структур бүлекчәләре составына керүе.

2. Үзенә буйсынган затның мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлыгы барлыкка килүе турында мәгълүм булган муниципаль вазыйфаны биләп торучы зат тарафыннан үзенә буйсынган зат тарафыннан мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу чаралары күрелмәү, ышаныч югалуга бәйле рәвештә эштән чыгарылырга (вазыйфадан азат ителергә) тиеш.

3. 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, тиешле вазифаны биләгән җирле үзидарә органы тарафыннан муниципаль вазыйфаны биләп торучы затка карата куллану, эштән чыгару (вазыйфадан азат итү) рәвешендәге чара турында белешмәләр җирле үзидарә органы тарафыннан кертелә.

## VI бүлек. ҖИРЛЕ АДМИНИСТРАЦИЯ

### 52 статья. Җирле администрация

1. Федераль законнар нигезендә шәһәр җирлеге башкарма-боеру органы вәкаләтләрен үтәү район Башкарма комитетына йөкләнә.

2. Район Башкарма комитеты җитәкчесе әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләрне үтәү өлешендә шәһәр җирлеге Советына контрольдә тора һәм хисап тота.

## VII бүлек. Шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы һәм район Башкарма комитеты арасындагы мөнәсәбәтләр

### 53 статья. Шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы һәм район Башкарма комитетының үзара хезмәттәшлек нигезләре

1. Әлеге Уставта билгеләнгән вәкаләтләрне бүлү нигезендә шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы һәм район Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль гамәлгә ашыралар.

2. Шәһәр җирлеге Советы һәм район Башкарма комитеты законнарда, әлеге Уставта билгеләнгән формаларда, шәһәр җирлегенең икътисадый һәм социаль үсеше процесслары белән нәтиҗәле идарә итү максатларында һәм аның халкы мәнфәгатьләрендә хезмәттәшлек итәргә тиеш.

3. Шәһәр җирлеге Советы һәм район Башкарма комитеты (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең башкарма-боеру органы вәкаләтләрен

башкарганда) кабул ителгән хокукый актларны кул куелган көннән җиде көн эчендә бер-берсенә җибәрәләр.

4. Шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Башлыгы район Башкарма комитеты Җитәкчесенә район Башкарма комитеты Җитәкчесенең, район Башкарма комитетының башка вазыйфаи затларының хокукый актларын кабул итү, гамәлдән чыгару, үзгәртү яки өстәмәләр кертү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять белдерергә хокуклы.

5. Район Башкарма комитеты җитәкчесе (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең башкарма-боеру органы вәкаләтләрен үтәгәндә) шәһәр җирлеге Советына, шәһәр җирлеге Башлыгына шәһәр җирлеге Советының, шәһәр җирлеге Башлыгының хокукый актларын кабул итү, гамәлдән чыгару, үзгәртү яки өстәмәләр кертү турындагы тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, шулай ук аларга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

6. Шәһәр җирлеге Башлыгы район Башкарма комитеты Җитәкчесенә шәһәр җирлеге Советының эш планнарын һәм шәһәр җирлеге Советы карарлары проектларын шәһәр җирлеге Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

7. Шәһәр җирлеге Советы һәм аның органнары утырышларында, шәһәр җирлеге Башлыгы үткәрә торган утырышларда киңәш бирү тавышы хокукы белән район Башкарма комитеты җитәкчесе (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма-боеру органы вәкаләтләрен башкарганда), аның урынбасарлары яисә алар тарафыннан вәкаләтле затлар катнашырга хокуклы. Район Башкарма комитетының вазыйфаи затлары (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең башкарма-боеру органы вәкаләтләрен башкарганда), язмача чакыру булганда, шәһәр җирлеге Советы утырышларында катнашырга тиеш.

8. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе үткәргән утырышларда шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Советы депутатлары катнашырга хокуклы.

54 статья. Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары арасында бәхәсләрне хәл итү

Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары арасында, аларның вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча, бәхәсләр килештерү процедураларын үткәрү юлы белән йә суд тәртибендә хәл ителә.

## VIII бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАННАРЫ ҺӘМ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ОРГАННАРЫ

55 статья. Шәһәр җирлегенең ревизия комиссиясе

1. Шәһәр җирлегенең ревизия комиссиясе даими эшләүче, коллегиаль финанс контроле органы булып тора, аның вәкаләтләрен районның Контроль-хисап палатасы башкара.

2. Район Контроль-хисап палатасының оештыру һәм эшчәнлек тәртибе, вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән, 2011 елның 7 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 6-ФЗ номерлы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, район Советы белән расланган Район контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмәсе, башка муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнә.

Федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, Районның контроль-хисап палатасы эшен һәм эшчәнлеген хокукый җайга салу, шулай ук Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.

## IX бүлек. САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

### 56 статья. Шәһәр җирлегенең Сайлау комиссиясе

1. Шәһәр җирлегенең Сайлау комиссиясе, шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасына керми торган, шәһәр җирлеге Советына депутатлар сайлауларын, җирле референдумны әзерләү һәм үткәрүне, шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирүне, шәһәр җирлеге чикләрен үзгәртү, шәһәр җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыручы муниципаль органы булып тора.

2. Шәһәр җирлегенең Сайлау комиссиясе Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы белән билгеләнгән тәртиптә шәһәр җирлеге Советы тарафыннан төзелә.

3. Шәһәр җирлеге Сайлау комиссиясенең вәкаләтләре срогы биш ел тәшкил итә.

4. Шәһәр җирлегенең Сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән 8 әгъза составында формалаша.

5. Шәһәр җирлеге Сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү шәһәр җирлеге бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән күздә тотыла.

6. Шәһәр җирлеге Сайлау комиссиясенең вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән җайга салына.

7. Шәһәр җирлеге Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча, шәһәр җирлеге Сайлау комиссиясенең вәкаләтләре территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнә ала.

## X бүлек. ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНЕҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ҺӘМ МУНИЦИПАЛЬ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ГРАЖДАН - ХОКУКЫЙ ҺӘМ ФИНАНС НИГЕЗЛӘРЕ

57 статья. Шәһәр җирлегенең юридик зат хокукларына ия булган җирле үзидарә органнары

1. Федераль закон һәм әлеге Устав нигезендә юридик зат хокуклары шәһәр җирлеге Советына бирелә.

58 статья. Юридик затлар буларак шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары

1. Шәһәр җирлеге Башлыгы, район Башкарма комитеты Җитәкчесе (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең башкарма-боеру органы вәкаләтләрен башкарганда) шәһәр җирлеге исеменнән мөлкәти һәм башка хокуклар һәм бурычларны сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, судта ышанычнамәдән башка чыгыш ясарга мөмкин.

2. Шәһәр җирлегенең юридик зат хокукына ия булган җирле үзидарә органнары, идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен, барлыкка килә торган муниципаль казна учреждениеләре булып тора һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак дәүләт теркәве узарга тиеш.

59 статья. Җирле үзидарә органнарын һәм шәһәр җирлеге муниципаль органнарын финанслау

1. Җирле үзидарә органнары һәм шәһәр җирлеге муниципаль органнары эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү бары тик шәһәр җирлеге бюджетының үз керемнәре хисабына гына гамәлгә ашырыла.

2. Законда, әлеге Уставта, шәһәр җирлеге Советы карарларында каралган очракларда җирле үзидарә органнары һәм шәһәр җирлеге муниципаль органнары эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар шәһәр җирлеге бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.

## XI бүлек ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫНА ҺӘМ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРЫН БИЛӘҮЧЕ БАШКА ЗАТЛАРГА БИРЕЛӘ ТОРГАН СОЦИАЛЬ ҺӘМ БАШКА ГАРАНТИЯЛӘР

60 статья. Даими нигездә эшләүче шәһәр җирлеге Башлыгына һәм аның урынбасарына бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр

Даими нигездә эшләүче шәһәр җирлеге Башлыгы һәм аның урынбасары эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре 2009 елның

12 февралендәге «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 15-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә.

61 статья. Шәһәр җирлеге Советы депутатына, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр

Шәһәр җирлеге Советы депутатларына, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы һәм шәһәр җирлеге Советы карарлары белән билгеләнә.

62 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Советы депутатлары кагылгысызлык гарантияләре

1. Шәһәр җирлеге Советы депутатларының, шул исәптән шәһәр җирлеге Башлыкларының, аның урынбасарының, аларны җинаять яки административ җаваплылыкка тартканда, кулга алганда, тентегәндә, сорау алганда, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль гамәлләр кылганда, шулай ук депутатларга, алар биләгән торак һәм (яки) хезмәт урынына, багажларына, шәхси һәм хезмәт транспорт чараларына, узара язышкан хатларына, алар куллана торган элемтә чараларына, документларына карата оператив-эзләү чаралары үткәрелгәндә хокук гарантияләре федераль законнар белән билгеләнә.

2. Федераль закон нигезендә шәһәр җирлеге Советы депутаты әйтелгән фикер, тавыш биргәндә белдерелгән позициясе һәм аның статусына туры килә торган башка гамәлләр өчен, шул исәптән аның вәкаләтләре вакыты чыкканнан соң да, җинаять яисә административ җаваплылыкка тартыла алмый. Әлеге нигезләмә шәһәр җирлеге советы депутаты тарафыннан халык алдында мыскыллау, яла ягу яисә башка хокук бозуларга юл куелган очракларга кагылмый, алар өчен җаваплылык федераль закон белән каралган.

## XII бүлек. ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҺӘМ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ, АЛАРНЫҢ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ КОНТРОЛЬ ҺӘМ КҮЗӘТҮ

63 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Җирле үзидарә органнары һәм шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары федераль законнар нигезендә шәһәр җирлеге халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында җаваплы.

64 статья. Шәһәр җирлеге Советы депутатларының шәһәр җирлеге халкы алдында җаваплылыгы

1. Шәһәр җирлеге Советы депутатларының, шул исәптән шәһәр җирлеге Башлыкларының, шәһәр җирлеге халкы алдында җаваплылыгы, хокукка каршы карарлар кабул итү яки суд тәртибендә расланган очракта, хокукка каршы гамәлләр кылу аркасында шәһәр җирлеге халкының ышанычын югалту нәтиҗәсендә барлыкка килә.

2. Ышанычын югалткан шәһәр җирлеге Советы депутаты, шул исәптән шәһәр җирлеге Башлыгы, әлеге Уставта каралган очракларда һәм тәртиптә шәһәр җирлеге сайлаучылары тарафыннан кире чакыртып алынырга мөмкин.

65 статья. Җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының дәүләт алдында җаваплылыгы

Шәһәр җирлеге Советын таркату нигезләре һәм тәртибе, шәһәр җирлеге Башлыгы вазифасыннан читләштерү һәм отставкага җибәрү тәртибе 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнә.

Җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының дәүләт алдында җаваплылыгы, Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституцион законнарны, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен, әлеге Уставны бозган очракта, шулай ук күрсәтелгән органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан аларга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә башкармаган очракта, тиешле суд карары нигезендә барлыкка килә.

66 статья. Физик һәм юридик затлар алдында шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдында җаваплылыгы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә барлыкка килә.

## XIII бүлек. ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ

67 статья. Шәһәр җирлегенең муниципаль хокукый актлары системасы

1. Шәһәр җирлегенең муниципаль хокукый актлары системасына түбәндәгеләр керә:

1) шәһәр җирлеге Уставы, җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар;

2) шәһәр җирлеге Советының норматив һәм башка хокукый актлары;

3) шәһәр җирлеге Башлыгының, район Башкарма комитетының хокукый актлары (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең башкарма-боеру органы һәм җирле үзидарәнең әлеге Уставта каралган башка органнары һәм вазыйфаи затларының вәкаләтләрен үтәгәндә).

2. Шәһәр җирлеге Уставы һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән карарлар муниципаль хокукый актлар системасында югары юридик көч актлары булып тора, турыдан-туры гамәлдә була һәм шәһәр җирлегенең бөтен территориясендә кулланыла.

Башка муниципаль хокукый актлар әлеге Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актларга каршы килергә тиеш түгел.

3. Шәһәр җирлеге Уставы Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм алар нигезендә кабул ителә торган муниципаль хокукый актның әлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында каршылыгы рөхсәт ителми.

4. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар шәһәр җирлегенең бөтен территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш.

5. Муниципаль хокукый актларны үтәмәгән өчен гражданнар, оешма җитәкчеләре, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары федераль законнар һәм административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә җавап тоталар.

6. Шәһәр җирлегенең муниципаль хокукый актлары Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, башка норматив хокукый актларына каршы килергә тиеш түгел.

7. Муниципаль хокукый актлар тиешле муниципаль хокукый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары яки җирле үзидарәнең вазифаи затлары тарафыннан, андый органнар яки вазифаи затлар бетерелгән яки шул органнар яки вазифаи затларның вәкаләтләре исемлеге үзгәргән очракта – муниципаль хокукый актлар гамәлдән чыгарылган яки аларның көче туктатылган вакытта тиешле муниципаль хокукый актны кабул итү (чыгару) вәкаләтләре бирелгән җирле үзидарә органнары яки вазифаи затлары тарафыннан, шулай ук суд тарафыннан , ә җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәүне җайга салу өлешендә – муниципаль хокукый актлар Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы якиТатарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан гамәлдән чыгарыла яки аларның көче вакытлыча туктатып торыла ала.

8. Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын саклау буенча вәкаләтле зат Россия Федерациясенең Эшмәкәрләр хокукларын саклау буенча вәкаләтле затлары турындагы закон нигезендә бирелгән тиешле күрсәтмәне алган очракта, норматив характерда

булмаган муниципаль хокукый актның көче аны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органы яки җирле үзидарә органының вазифаи заты тарафыннан тиз арада туктатыла. Алынган күрсәтмәнең үтәлеше турында район Башкарма комитеты яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә - өч көн, ә шәһәр җирлеге Советына алар карар кабул иткән көннән өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

9. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив-хокукый актларга, эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигезсез рәвештә кыенлык тудыручы нигезләмәләрне ачыклау максатыннан, Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары уздыра торган экспертиза үткәрелергә тиеш.

68 статья. Гражданнарның үз ихтыярларын турыдан-туры белдерү юлы белән кабул ителгән карарлар

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры муниципаль берәмлек гражданнары тарафыннан хәл итү җирле референдумда халыкның үз ихтыярын турыдан-туры белдерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Әгәр шәһәр җирлегендә яшәүчеләрне үз ихтыярын турыдан-туры белдерү юлы белән кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль хокукый акт кабул итү (чыгару) таләп ителсә, шәһәр җирлегенең үз вәкаләтләренә әлеге актны кабул итү (чыгару) кергән җирле үзидарә органы яки җирле үзидарәнең вазифаи заты, референдумда кабул ителгән карар гамәлгә кергән көннән алып 15 көн эчендә, әлеге муниципаль хокукый актны әзерләү һәм (яки) кабул итү срогын билгеләргә бурычлы. Күрсәтелгән срок өч айдан да артык була алмый.

3. Муниципаль хокукый актның гражданнарның турыдан-туры ихтыярын белдерү юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәк булган срогын бозу шәһәр җирлеге Башлыгын кире чакыртып алу яисә шәһәр җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез булып тора.

69 статья. Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актларларның төрләре

1. Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү йөзеннән түбәндәге муниципаль хокукый актларны чыгара:

1) шәһәр җирлеге Советы-шәһәр җирлеге Советы карарлары, шәһәр җирлеге Советы Президиумы-шәһәр җирлеге Советы Президиумы карарлары;

2) шәһәр җирлеге Башлыгы-шәһәр җирлеге Башлыгы карарлары һәм боерыклары;

3) район Башкарма комитеты Җитәкчесе – район Башкарма комитеты карарлары һәм боерыклары (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма-боеру органы вәкаләтләрен үтәү турында).

2. Шәһәр җирлегенең башка вазыйфаи затлары үз вәкаләтләре чикләрендә әлеге Уставта, башка муниципаль хокукый актларда билгеләнгән, аларның статусын билгели торган каралар һәм боерыклар чыгара.

70 статья. Муниципаль хокукый актларны әзерләү

1. Муниципаль хокукый актлар проектлары шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Советы депутатлары, район Башкарма комитеты Җитәкчесе (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма-күрсәтмә органы вәкаләтләрен үтәгәндә), Зеленодольск шәһәр прокуроры, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре, шәһәр җирлегенең Ревизия комиссиясе, шулай ук шәһәр җирлеге Уставы белән билгеләнгән хокукый акт чыгару инициативасы субъектлары тарафыннан кертелә ала.

2. Муниципаль хокукый актлар проектларын кертү тәртибе, аларга кушып бирелә торган документлар исемлеге һәм формасы, күрсәтелгән проектлар кертелгән, җирле үзидарә органының яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

3. Зеленодольск шәһәр прокуроры үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында, гамәлдәге норматив хокукый актларны камилләштерү зарурлыгын билгеләгәндә, закон чыгару инициативасы хокукына ия булган шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнарына муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү, өстәмә кертү, гамәлдән чыгару яки кабул итү турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

4. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив-хокукый акт проектларына, Татарстан Республикасы законы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, җирле үзидарә органнары уздыра торган җайга салу йогынтысы бәяләнергә тиеш.

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү җирле үзидарә органнары (җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары) тарафыннан 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

5. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив-хокукый актларга, экспертиза эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруга нигезсез рәвештә кыенлык тудыручы нигезләмәләрне ачыклау максатыннан үткәрелә.

6. Муниципаль норматив хокукый актларга Экспертиза «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ

номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә тиешле җирле үзидарә органнарында расланган планнар нигезендә җирле үзидарә органнары (җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары) тарафыннан үткәрелә.

71 статья. Шәһәр җирлеге Советының хокукый актлары

1. Шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Советы Президиумы аның компетенциясенә кергән федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, шәһәр җирлеге Уставы белән кертелгән мәсьәләләр буенча шәһәр җирлеге территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиешле кагыйдәләрне, шәһәр җирлеге Советы Регламентын, шәһәр җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү турында карар кабул итә, шулай ук федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, шәһәр җирлеге Уставы белән аның компетенциясенә кергән башка мәсьәләләр буенча шәһәр җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар кабул итә.

2. Шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Советы Президиумы карарлары, законнарда, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, шәһәр җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3. Шәһәр җирлеге Советының җирле салымнар һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгаруны, шәһәр җирлеге бюджеты акчаларыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тоткан карарлары бары тик район Башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма-күрсәтмә органы вәкаләтләрен үтәгәндә), яки аның бәяләмәсе булганда гына шәһәр җирлеге Советына кертелергә мөмкин. Әлеге бәяләмә карар проекты Башкарма комитетка тәкъдим ителгән көннән алып утыз көн эчендә шәһәр җирлеге Советына тапшырыла.

4. Шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Советы Президиумы карарлары кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан имзалана һәм әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерелә.

72 статья. Шәһәр җирлеге Башлыгының хокукый актлары

Шәһәр җирлеге Башлыгы законнарда, әлеге Уставта, шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Советы Президиумы карарлары белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр һәм шәһәр җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру буенча хокукый актлар чыгара. Шәһәр җирлеге Башлыгы әлеге Уставның үз компетенциясенә кергән башка мәсьәләләр буенча 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар нигезендә карарлар һәм боерыклыр чыгара.

73 статья. Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керүе тәртибе

1. Шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлеге Советы Президиумы карарлары, шәһәр җирлеге Башлыгы кул куйган көннән соң 10 көн узгач, үз көченә керә, әгәр дә карарның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса.

Шәһәр җирлеге Советының салымнар һәм җыемнар турындагы хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

Шәһәр җирлеге Советының шәһәр җирлеге Уставын кабул итү яки әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарлары Федераль законда, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.

2. Шәһәр җирлеге Башлыгының, Җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затларының хокукый актлары, әгәр актларда башкасы билгеләнмәгән булса, аларга кул куелган көннән үз көченә керә.

3. Муниципаль берәмлек гамәлгә куйган оешмаларның хокукый статусын билгели торган, кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, муниципаль хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасыннан файдаланырга хокуклы. Рәсми челтәр басмасында тулы текст басылып чыккан (урнаштырылган) очракта, матбугат басмасында аның күләмле график һәм таблица рәвешендәге кушымталары китерелмәскә мөмкин.

4. Һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары булырга тиеш: аның исеме, кул кую датасы (шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән хокукый актлар өчен – шулай ук аны җирлек Советы кабул иткән дата), теркәү номеры, хокукый актка имза салган вазыйфаи затның исеме, мөһере.

5. Шәһәр җирлеге Советы карары, аның үтәлеше турында, җирле салымнар һәм җыемнар билгеләү турында, шәһәр җирлеге Советы Регламенты, шәһәр җирлеге Советы Президиумы, шәһәр җирлеге Башлыгы, район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан кабул ителгән башка норматив хокукый актлар (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең башкарма-боеру органы вәкаләтләрен үтәгәндә) рәсми рәвештә басылып чыгарга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

6. Муниципаль сайлаулар, җирле референдум, шәһәр җирлеге Советы депутатын кире чакыртып алу буенча тавыш бирү, чикләрне үзгәртү, шәһәр җирлеген үзгәртеп кору, шәһәр җирлеге Башлыгын һәм аның урынбасарын сайлау мәсьәләсе буенча норматив хокукый актлар һәм законнар нигезендә башка актлар мәҗбүри рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

7. Законнар яки әлеге Устав нигезендә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) мәҗбүри булмаган норматив булмаган муниципаль хокукый актлар, аларны чыгарган җирлек үзидарә органнары яки яисә җирле үзидарә

вазыйфаи затлары карары буенча, бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) мөмкин.

8. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелә.

9. Рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү)

1) муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»; (http://pravo.tatarstan.ru) һәм (яки)

- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм (яки)

- «Зеленодольская правда» һәм (яки) «Яшел Үзән»газеталарында хокукый акт текстын бастырып чыгару.

2). муниципаль хокукый актлар текстын «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хокукый актны яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару дип аның тулы текстын беренче бастырып чыгару санала.

10. Барлык муниципаль норматив хокукый актлар җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән көннән ун эш көне эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) - муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен урнаштырыла .

74 статья. Шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен карап тоту

1. Шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре - Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары, шулай ук Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары нигезендә шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү элементларына һәм төзекләндерүгә карата таләпләрне, шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү буенча чаралар исемлеген, аларны үткәрү тәртибен һәм вакытын билгеле торган муниципаль хокукый акт;

2. Шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре шәһәр җирлеге Советы тарафыннан раслана.

3. Шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре түбәндәге мәсьәләләрне җайга сала ала:

1) гомуми файдаланудагы территорияләрне карап тоту һәм мондый территорияләрдән файдалану тәртибен;

2) биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның фасад һәм киртәләү конструкцияләренең тышкы төрен;

3) төзекләндерү элементларын проектлау, урнаштыру, карап тоту һәм торгызу, шул исәптән җир эшләрен башкарганнан соң да;

4) шәһәр җирлеге территориясен, шул исәптән биналарны, төзелмәләрне, корылмаларны архитектур яктыртуны да кертеп, яктыртуны оештыру;

5) торак пунктлар чикләрендә урнашкан газоннарны, чәчәк түтәлләрен һәм үлән үсемлекләре белән башка территорияләрне булдыру, карап тоту, торгызу һәм саклау тәртибен дә кертеп, шәһәр җирлеге территориясен яшелләндерүне оештыру;

6) шәһәр җирлеге территориясендә мәгълүмат урнаштыру, шул исәптән урам исемнәре һәм йорт номерлары, элмә такталары куелган күрсәткечләр урнаштыру;

7) балалар һәм спорт мәйданчыкларын, хайваннарны урамда йөртү өчен мәйданчыклар, парковкалар (парковка урыннары), кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту;

8) җәяүлеләр коммуникацияләрен оештыру, шул исәптән тротуарларны, аллеяларны, юлларны, сукмакларны;

9) күрсәтелгән территория буенча инвалидларның һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү максатларында шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү;

10) шәһәр җирлеге территориясен җыештыру, шул исәптән кышкы чорда;

11) яңгыр сулары агынтыларын оештыру;

12) җир эшләрен үткәрү тәртибе;

13) биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның, җир кишәрлекләренең (милекчеләреннән һәм (яки) башка законлы хуҗаларының (мондый йортлар чикләре буенча төзелмәгән җир кишәрлекләре милекчеләреннән һәм (яки) башка законлы хуҗаларыннан тыш) тирә-юнь территорияләрен карап тотуда катнашу;

14) Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртип нигезендә тирә-юнь территорияләре чикләрен билгеләү;

15) шәһәр җирлеге территориясен бәйрәмчә бизәү;

16) шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруда гражданнар һәм оешмаларның катнашу тәртибе;

17)шәһәр җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту.

## XIV бүлек. МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТ

### 75 статья. Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу

Муниципаль хезмәтне хокукый җайга салу, муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләрне, муниципаль хезмәткәр статусын билгеләү, муниципаль хезмәт үтү шартлары һәм тәртибе Федераль закон, шулай ук аның нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законы, әлеге

Устав һәм шәһәр җирлегенең башка муниципаль хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

76 статья. Муниципаль хезмәт вазыйфалары

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – муниципаль берәмлек Уставы нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органындагы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратындагы вазыйфа, аңа җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен башкаруны тәэмин итү бурычларының билгеләнгән даирәсе керә.

2. Муниципаль хезмәт вазыйфалары Татарстан Республикасы Законы белән расланган Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә.

3. Җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының штат расписаниесен төзегәндә һәм раслаганда Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрында каралган муниципаль хезмәт вазыйфалары атамалары кулланыла.

77 статья. Муниципаль хезмәт

1. Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт - хезмәт шартнамәсе (контракты) төзү юлы белән биләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфаларында даими нигездә гамәлгә ашырыла торган гражданнарның һөнәри эшчәнлеге.

2. Муниципаль берәмлек муниципаль хезмәткәр өчен эшкә яллаучы булып тора, аның исеменнән эшкә яллаучы вәкаләтләрен эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) гамәлгә ашыра. Эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле муниципаль берәмлек Башлыгы, җирле үзидарә органы җитәкчесе, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе яисә эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) вазыйфаларын башкарырга вәкаләтле бүтән зат булырга мөмкин.

3. Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт Россия Федерациясе Конституциясе, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, әлеге Устав, шәһәр җирлеге Советы карары белән расланган, шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә, шәһәр җирлегенең башка муниципаль хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәткәрләргә 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль Федераль законда каралган үзенчәлекләре белән хезмәткә кагылышлы законнарның гамәлдә булуы кагыла.

4. Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәтне финанслау шәһәр җирлеге бюджеты хисабына башкарыла

78 статья. Муниципаль хезмәткәр

1. Муниципаль хезмәткәргә 18 яшькә җиткән, җирле бюджет акчалары исәбеннән түләнә торган акчалата тулаем хезмәт хакы алып, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфасы бурычларын башкаручы граждан.

2. Җирле үзидарә органнары, шәһәр җирлеге сайлау комиссиясе эшчәнлеген техник тәэмин итү буенча вазыйфаларны башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләми һәм муниципаль хезмәткәрләр булмый.

79 статья. Муниципаль хезмәткә урнашу

1. Муниципаль хезмәткә 18 яшькә җиткән, 2007 елның 2 мартындагы Россия Федерациясе дәүләт телен белгән һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килә торган, әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләр сыйфатындагы хәлләр булмаганда урнашырга хокуклы.

Муниципаль хезмәткә урнашканда, шулай ук аны үткәндә, җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи дәрәҗәсенә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, нинди иҗтимагый берләшмәдән булуына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка хәлләргә карап, теләсә нинди турыдан-туры яисә бүтән рәвешле чикләүләр яки өстенлекләр билгеләү рөхсәт ителми.

2. Граждан түбәндәге очракларда муниципаль хезмәткә алына алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттә була алмый:

1) үз көченә кергән суд карары белән эшкә яраксыз яки чикле рәвештә яраклы дип танылса;

2) үз көченә кергән суд хөкеме белән муниципаль хезмәт вазыйфасының вазыйфаи бурычларын үтәү мөмкинлеген калдырмый торган җәзага тартылса;

3) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы гражданның вазыйфаи бурычлары яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычлары дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләр белән бәйле булса, әлеге белешмәләр белән эшләүгә рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасын үтүдән баш тартса;

4) муниципаль хезмәткә керүгә яки аны узуга комачаулаучы һәм медицина оешмасы бәяләмәсе белән расланган авыруы булса. Диспансерлаштыруны узу тәртибе, мондый авырулар исемлеге һәм медицина

оешмасын төзү рәвеше Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә;

5) җирле администрацияне җитәкләүче муниципаль берәмлек башлыгы белән якын кардәшлектә яки үги туганлыкта (ата-анасы, ире (хатыны), балалары, абыйлары, апалары, шулай ук ир белән хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары, балалары һәм балаларының ире (хатыны) булса, әгәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү әлеге вазыйфаи затка турыдан-туры буйсыну яисә аның контрольлегендә булу белән бәйле булганда, яисә муниципаль хезмәткәр белән, әгәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү әлеге муниципаль хезмәткәрләрнең бер-берсенә турыдан-туры буйсыну яисә бер-берсенең контрольлегендә булу белән бәйле булганда;

6) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылса, чит дәүләт гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнаша торган чит дәүләт гражданлыгы туктатылса, чит дәүләт гражданлыгын алса яки чит дәүләт гражданлыгына ия Россия Федерациясе гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашмый торган чит дәүләт территориясендә Россия Федерациясе гражданының яшәүгә рөхсәт яисә даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алса;

7) чит дәүләт (чит дәүләтләрнең) гражданлыгы булса, муниципаль хезмәткәр чит дәүләт гражданына муниципаль хезмәттә булу хокукы бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит дәүләт гражданы булып торган очраклардан тыш;

8) муниципаль хезмәткә урнашканда ялган документлар яисә күрәләтә ялган белешмәләр тапшырса;

9) муниципаль хезмәткә урнашканда «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда, «Коррупциягә каршылык турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «Коррупциягә каршылык турында» Федераль закон) һәм башка федераль законнарда каралган белешмәләрне тапшырмаса яисә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырса.

10) шәһәр җирлеге Уставының 89 статьясында каралган белешмәләрне тапшырмаса;

11) законлы нигезләр булмыйча торып, ул чакыру комиссиясе бәяләмәсе нигезендә чакырылыш буенча хәрби хезмәт узмаган дип танылса (контракт буенча хәрби хезмәт узган гражданнардан тыш), – Татарстан Республикасының чакыру комиссиясенә күрсәтелгән бәяләмәгә шикаять бирү өчен билгеләнгән вакыт тәмамланган көннән алып 10 ел дәвамында, әгәр Татарстан Республикасы чакыру комиссиясенең әлеге бәяләмәсе һәм (яисә) карары гражданның шушы бәяләмәгә шикаяте буенча судка бирелгән булса, – Татарстан Республикасының чакыру комиссиясе бәяләмәсе һәм (яисә) карары чыгарылганда гражданның күрсәтелгән бәяләмәгә шикаять бирү хокуклары бозылмаган дип тану турындагы суд карары үз көченә кергән көннән алып 10 ел дәвамында.

3. Граждан муниципаль хезмәткә урнашканда түбәндәгеләрне тапшыра:

1) муниципаль хезмәткә урнашу һәм муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү турында үтенече булган гаризасын;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форма буенча үз кулы белән тутырылган һәм имзасы салынган анкетасын;

3) паспорт;

4) хезмәт кенәгәсен һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турындагы белешмәләрне (Хезмәт кодексының 66.1 статьясы), хезмәт шартнамәсен (контрактын) беренче мәртәбә төзү очракларыннан тыш;

5) белеме турындагы документын;

6) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документны, шул исәптән электрон документ формасында;

7) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклыгын;

8) хәрби исәпкә кую документларын - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

9) муниципаль хезмәткә урнашуга комачауларлык авыруы булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсен;

10) муниципаль хезмәткә урнашу елы алдындагы бер ел эчендә керемнәре турындагы, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакындагы белешмәләрен;

11) шәһәр җирлеге Уставының 89 статьясында каралган белешмәләрне.

12) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документларны;

4. Граждан билгесез срокка яки биш елдан да артмаган срокка төзелүче хезмәт шартнамәсе шартларында муниципаль хезмәткә урнаша.

5. Федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында, шулай ук әлеге Уставта һәм шәһәр җирлегенең муниципаль хезмәте турындагы нигезләмәдә каралган очракларда муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләү конкурс нигезендә башкарыла.

6. Гражданның муниципаль хезмәткә урнашуы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую турында эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) муниципаль хокукый акты белән рәсмиләштерелә.

7. Муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куелганнан соң муниципаль хезмәткәргә хезмәт таныклыгы бирелә. Муниципаль хезмәткәр таныклыгын бирү тәртибе һәм формасы шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан раслана.

8. Муниципаль хезмәт узу муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшендә чагыла.

9. Граждан муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын кардәшлектә яки үги туганлыкта (ата-анасы, ире (хатыны), балалары, абыйлары, апалары, шулай ук ир белән

хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары, балалары һәм балаларның ире яисә хатыны) булса, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларына билгеләп куела алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын били алмый.

80 статья. Муниципаль хезмәткәрнең хокуклары һәм бурычлары

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль хезмәтнең үзе били торган вазыйфасы буенча хокукларын һәм бурычларын билгели торган документлар белән, вазыйфаи бурычларын үтәү сыйфатын бәяләү критерийлары һәм хезмәт буенча үсү шартлары белән танышырга;

2) вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле оештыру-техник шартлар белән тәэмин ителергә;

3) хезмәт өчен түләүгә һәм хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турындагы законнар һәм хезмәт шартнамәсе (контракты) нигезендә башка түләүләргә;

4) Эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләүне, ял көннәре һәм эш көннәре булмаган бәйрәм көннәре, шулай ук ел саен түләүле отпусклар бирүне тәэмин итә торган ялга;

5) вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә алырга, шулай ук җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертергә;

6) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста үз инициативасы белән катнашырга;

7) муниципаль хокукый акт нигезендә җирле бюджет акчалары исәбеннән өстәмә һөнәри белем алуга;

8) үзенең персональ белешмәләренең яклануына;

9) үзенең шәхси эшнамәсендәге барлык материаллар, һөнәри эшчәнлеге турындагы бәяләүләр һәм башка документлар белән аларны шәхси эшнамәсенә керткәнче танышырга, шулай ук шәхси эшнамәсенә үзенең язма аңлатмаларын кушып бирергә;

10) профсоюз булдыру хокукын да кертеп, үз хокукларын, социаль-икътисадый һәм һөнәри мәнфәгатьләрен яклау өчен берләшергә;

11) хезмәт законнары нигезендә индивидуаль хезмәт бәхәсләрен каратуына, муниципаль хезмәттәге үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, аларның бозылуы турында судка шикаять белдерүне дә кертеп, яклатуына;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия белән тәэминатына.

2. Муниципаль хезмәткәр, җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче муниципаль хезмәткәрдән тыш, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) алдан язмача хәбәр итеп, түләүле бүтән эш башкарырга хокуклы, әгәр дә бу мәнфәгатьләр конфликтын китереп чыгармаса һәм 2007

елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.

3 Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

2) вазыйфаи инструкция нигезендә вазыйфаи бурычларны үтәргә;

3) вазыйфаи бурычларын башкарганда, расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка хәлләргә карамастан кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

4) җирле үзидарә органында, шәһәр җирлегенең сайлау комиссиясе аппаратында эчке хезмәт тәртибе билгеләнгән кагыйдәләрен, вазыйфаи инструкцияне, хезмәттәге мәгълүмат белән эшләү тәртибен үтәргә;

5) вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен сакларга;

6) дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә үзенә мәгълүм булган белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә, намусына һәм абруена кагылышлы белешмәләрне фаш итмәскә;

7) дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән вазыйфаи бурычларын үтәү өчен үзенә тапшырылган мөлкәтне сакларга;

8) үзе һәм гаилә әгъзалары турында Россия Федерациясе законнарында каралган белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;

9) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу турында Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан көнне яисә чит ил гражданлыгын алу хакында чит ил гражданлыгын алган көнне яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) хәбәр итәргә;

10) 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, йөкләмәләрне башкарырга, тыюларны бозмаска;

11) вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерерлек шәхси кызыксынуы турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау чараларын күрергә

4. Муниципаль хезмәткәр үзенә хокукка яраксыз рәвештә бирелгән йөкләмәне үтәргә хокуксыз. Муниципаль хезмәткәр фикере буенча тиешле җитәкчедән хокукка яраксыз йөкләмә алынганда, муниципаль хезмәткәр, әлеге йөкләмәнең хокукка яраксызлыгын нигезләп, аны үтәгәндә бозылырга мөмкин булган федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының, муниципаль хокукый актларның

нигезләмәләрен күрсәтеп, үзенә йөкләмә биргән җитәкчегә язмача нигезләү тапшырырга тиеш. Җитәкче әлеге йөкләмәне язмача раслаган очракта, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тартырга тиеш. Хокукка яраксыз йөкләмә үтәлгән очракта, муниципаль хезмәткәр һәм бу йөкләмәне биргән җитәкче Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

81 статья. Муниципаль хезмәт белән бәйле тыюлар

1. Муниципаль хезмәткәргә муниципаль хезмәт үтүгә бәйле түбәндәгеләр тыела:

1) түбәндәге очракларда муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торырга:

а) Россия Федерациясенең дәүләт вазыйфасына йә Россия Федерациясе субъектының дәүләт вазыйфасына сайланса яисә билгеләп куелса, шулай ук дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп куелса;

б) муниципаль вазыйфага сайланса яисә билгеләп куелса;

в) профсоюз органында, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоз оешмасының сайланулы органында түләүле сайланулы вазыйфага сайланса;

2) коммерциягә карамаган яисә коммерциячел оешма белән идарә итүдә катнашырга, моңа түбәндәге очраклар керми:

а) түләүсез нигездә сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) яллаучы вәкиленең әлеге Кодексның $16^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәр берлеге органы, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләре съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш);

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советында, башка муниципаль берәмлекләрнең берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

г) муниципаль берәмлек исеменнән оешманың гамәлгә куючысы вәкаләтләрен башкару тәртибен яисә муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актларга таянып, муниципаль берәмлек гамәлгә куючысы (акционеры, катнашучысы) булган оешманың идарә органнарында

һәм ревизия комиссиясендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен кайгырту;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

2.1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

3) үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган йә аңа турыдан-туры буйсынган яисә аның контрольлегендә булган җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә өченче затлар эшләре буенча ышанычлы зат яисә вәкил булырга, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса;

4) физик һәм юридик затлардан вазыйфаи дәрәҗәгә бәйле рәвештә яисә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (бүләкләр, акчалата кызыксындыру, ссудалар, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачулар, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләр) алырга. Муниципаль хезмәткәрнең беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле алынган бүләкләре муниципаль милек булып танылa һәм, Россия Федерациясенең Гражданлык кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган җирле үзидарә органына, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә акт буенча тапшырыла. Беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына яисә башка рәсми чарага бәйле рәвештә алган бүләкне тапшырган муниципаль хезмәткәр аны Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

5) физик һәм юридик затларның акчалары исәбеннән командировкаларга йөрергә, җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, сайлау комиссияләре белән, шулай ук чит илләрнең дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары, халыкара һәм чит дәүләтләрнең коммерциячел булмаган оешмалары белән үзара килешүе нигезендә гамәлгә ашырыла торган командировкалардан тыш;

6) вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле булмаган максатларда матди-техник, финанс һәм башка тәэмин итү чараларыннан, башка муниципаль мөлкәттән файдаланырга;

7) үзенә вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә мәгълүм булган федераль законнар нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләргә караган белешмәләрне яисә хезмәт мәгълүматын фаш итәргә яисә муниципаль хезмәткә бәйле булмаган максатларда файдаланырга;

8) җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре эшчәнлегенә карата халык алдында фикерләр әйтүгә, фикер йөртүләргә һәм бәя бирүгә ирек бирергә, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында, әгәр болар аның вазыйфаи бурычларына кермәсә;

9) муниципаль берәмлек Башлыгының язмача рөхсәтеннән башка чит илләрнең, халыкара оешмаларның, шулай ук сәяси партияләрнең, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләрнең бүләкләрен, мактаулы һәм махсус

дәрәҗәләрен (фәнни дәрәҗәләрдән тыш) алырга, әгәр күрсәтелгән оешмалар һәм берләшмәләр белән үзара эшләү аның вазыйфаи бурычларына керсә;

10) сайлау алды агитациясендә, шулай ук референдум мәсьәләләрен агитацияләгәндә вазыйфаи дәрәҗәсенең өстенлекләреннән файдаланырга;

11) вазыйфаи дәрәҗәсен сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр мәнфәгатьләрендә файдаланырга, шулай ук халык алдында күрсәтелгән берләшмәләргә үзенең мөнәсәбәтен муниципаль хезмәткәр буларак белдерергә;

12) җирле үзидарә органнарында, башка муниципаль органнарда сәяси партияләр, дини һәм башка иҗтимагый берләшмәләр структураларын (профсоюз, шулай ук ветераннар һәм башка иҗтимагый үзешчәнлек органнарыннан тыш) төзергә яисә күрсәтелгән структураларны төзүдә ярдәм итәргә;

13) хезмәткә кагылышлы бәхәсләрне җайга салу максатларында вазыйфаи бурычларын үтәүне туктатырга;

14) идарә органнары, попечительлек яисә күзәтү советлары, чит дәүләтләрнең хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларының бүтән органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш йөртүче структур бүлекчәләре составына керергә, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

15) яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) язмача рөхсәтеннән башка бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит дәүләт оешмалары, чит дәүләт гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затларның акчалары исәбеннән финанслана торган түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә, әгәр Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса.

2. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфаны биләгән граждан, бу муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына оешмага муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре кергән булса, муниципаль хезмәттән җибәрелгәннән соң ике ел дәвамында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиянең Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә бирелгән ризалыгыннан башка әлеге оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфалар биләргә һәм (яисә) федераль законнарда каралган очракларда граждан-хокук шартнамәсе шартларында эш башкарырга хокуксыз.

3. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кертелгән вазыйфаны биләгән граждан, бу муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына оешмага муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре кергән булса, муниципаль хезмәттән җибәрелгәннән соң ике ел дәвамында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынында үз-үзләрен тоту таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссиянең

Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә бирелгән ризалыгыннан башка әлеге оешмада хезмәт шартнамәсе шартларында вазыйфалар биләргә һәм (яисә) федераль законнарда каралган очракларда граждан-хокук шартнамәсе шартларында эш башкарырга хокуксыз.

4. Җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр каршылыгын бетерү максатларында әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында ул күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый.

82 статья. Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә таләпләр

1. Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) муниципаль хезмәтнең үзе били торган вазыйфасы буенча хокукларын һәм бурычларын билгели торган документлар белән, вазыйфаи бурычларын үтәү сыйфатын бәяләү критерийлары һәм хезмәт буенча үсү шартлары белән танышырга;

2) вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле оештыру-техник шартлар белән тәэмин ителергә;

3) хезмәт өчен түләүгә һәм хезмәт законнары, муниципаль хезмәт турындагы законнар һәм хезмәт шартнамәсе (контракты) нигезендә башка түләүләргә;

4) Эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләүне, ял көннәре һәм эш көннәре булмаган бәйрәм көннәре, шулай ук ел саен түләүле отпусклар бирүне тәэмин итә торган ялга;

5) вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны билгеләнгән тәртиптә алырга, шулай ук җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертергә;

6) муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста үз инициативасы белән катнашырга;

7) Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә нигезендә җирле бюджет акчалары исәбеннән өстәмә һөнәри белем алуга;

8) үзенең персональ белешмәләренең яклануына;

9) үзенең шәхси эшнамәсендәге барлык материаллар, һөнәри эшчәнлеге турындагы бәяләүләр һәм башка документлар белән аларны шәхси эшнамәсенә керткәнче танышырга, шулай ук шәхси эшнамәсенә үзенең язма аңлатмаларын кушып бирергә;

10) профсоюз булдыру хокукын да кертеп, үз хокукларын, социаль-икътисадый һәм һөнәри мәнфәгатьләрен яклау өчен берләшергә;

11) хезмәт законнары нигезендә индивидуаль хезмәт бәхәсләрен каратуына, муниципаль хезмәттәге үз хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен, аларның бозылуы турында судка шикаять белдерүне дә кертеп, яклатуына;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә пенсия белән тәэминатына.

2. Муниципаль хезмәткәр, җирле администрация башлыгы вазыйфасын контракт буенча биләүче муниципаль хезмәткәрдән тыш, яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) алдан язмача хәбәр итеп, түләүле бүтән эш башкарырга хокуклы, әгәр дә бу мәнфәгатьләр конфликтын китереп чыгармаса һәм 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.

3 Муниципаль хезмәткәр түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

2) вазыйфаи бурычларны намус белән, югары профессиональ дәрәҗәдә үтәргә;

3) барлык физик һәм юридик затларга һәм оешмаларга бертигез, гадел мөнәсәбәт тәэмин итәргә, нинди дә булса иҗтимагый яисә дини берләшмәләргә, һөнәри яисә социаль төркемнәргә, гражданнарга һәм оешмаларга өстенлек бирмәскә һәм мондый берләшмәләргә, төркемнәргә, оешмаларга һәм гражданнарга карата аерым мөнәсәбәттә булмаска;

4) җирле үзидарә органында, шәһәр җирлегенең Сайлау комиссиясе аппаратында эчке хезмәт тәртибе билгеләнгән кагыйдәләрен, вазыйфаи инструкцияне, хезмәттәге мәгълүмат белән эшләү тәртибен үтәргә;

5) вазыйфаи бурычларын тиешенчә үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен сакларга;

6) дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә үзенә мәгълүм булган белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә, намусына һәм абруена кагылышлы белешмәләрне фаш итмәскә;

7) дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән вазыйфаи бурычларын үтәү өчен үзенә тапшырылган мөлкәтне сакларга;

8) үзе һәм гаилә әгъзалары турында Россия Федерациясе законнарында каралган белешмәләрне билгеләнгән тәртиптә тапшырырга;

9) Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгу турында Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыккан көнне яисә чит ил гражданлыгын алу хакында чит ил гражданлыгын алган көнне яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) хәбәр итәргә;

10) 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, йөкләмәләрне башкарырга, тыюларны бозмаска;

11) үзенең турыдан-туры җитәкчесенә вазыйфаи бурычларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган шәхси

кызыксынучанлык турында язмача хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау буенча чаралар күрергә.

12) вазыйфаи бурычларны намус белән башкаруга комачаулаучы нинди дә булса шәхси, мөлкәт (финанс) һәм башка мәнфәгатьләр йогынтысына бәйле гамәлләр кылмаска.;

13) сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр һәм башка оешмалар карарларының үз һөнәри хезмәт эшчәнлегенә йогынты ясау мөмкинлеген юкка чыгара торган нейтральлекне сакларга.;

14) гражданнар белән мөрәҗәгатьтә корректлылык күрсәтергә;

15) Россия Федерациясе халыкларының әхлакый гореф-гадәтләренә һәм тра-дицияләренә карата ихтирамлы булырга;

16) төрле этник һәм социаль төркемнәрнең, шулай ук конфессияләрнең мәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алырга;

17) милләтара һәм конфессияара татулыкка ярдәм итәргә;

18) муниципаль орган абруена яисә репутациясенә зыян китерерлек конфликтлы вәзгыятьләргә юл куймаска.

4. Җитәкче булып торган муниципаль хезмәткәр сәяси партияләр, башка иҗтимагый һәм дини берләшмәләр эшчәнлегендә муниципаль хезмәткәрләрне мәҗбүри катнаштыру очракларына юл куймаска тиеш.

5. Муниципаль хезмәткәр үзенә хокукка яраксыз рәвештә бирелгән йөкләмәне үтәргә хокуксыз. Муниципаль хезмәткәр фикере буенча тиешле җитәкчедән хокукка яраксыз йөкләмә алынганда, муниципаль хезмәткәр, әлеге йөкләмәнең хокукка яраксызлыгын нигезләп, аны үтәгәндә бозылырга мөмкин булган федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының, муниципаль хокукый актларның нигезләмәләрен күрсәтеп, үзенә йөкләмә биргән җитәкчегә язмача нигезләү тапшырырга тиеш. Җитәкче әлеге йөкләмәне язмача раслаган очракта, муниципаль хезмәткәр аны үтәүдән баш тартырга тиеш. Хокукка яраксыз йөкләмә үтәлгән очракта, муниципаль хезмәткәр һәм бу йөкләмәне биргән җитәкче Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

83 статья. Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру

1.Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвачы гражданнар, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән тәртиптә, вакытта һәм формада тапшырыла.

2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль вазыйфаны биләүче муниципаль хезмәткәр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшыру тәртибе һәм формасы буенча үзенең чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары хакында белешмәләр тапшырырга тиеш.

3. Муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм 2008 елның 25 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Президентының норматив хокукый актларында, әлеге Кодекста, Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган тәртиптә башкарыла.

4. Муниципаль хезмәткәрнең үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне тапшыру мәҗбүри булып та, аларны тапшырмау йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән җибәрүгә китерерлек хокук бозу булып санала.

5. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвачы гражданнар тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, күрсәтелгән вазыйфаларны биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткә урнашканда Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә гражданнар тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан чикләүләрнең һәм тыюларның, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрнең үтәлүен, аларның 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән бурычларны үтәвен тикшерү Татарстан Республикасы Президентының норматив хокукый актларында билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

84 статья. Муниципаль хезмәткәрне кызыксындыру

1. Муниципаль хезмәткәр үзенең вазыйфаи бурычларын намуслы һәм нәтиҗәле үтәгән, мактауга лаек булып хезмәт узган, аеруча мөһим һәм

катлаулы йөкләмәләрне үтәгән өчен, аңа карата түбәндәге кызыксындыру төрләре кулланылырга мөмкин:

1) рәхмәт белдерү;

2) бер мәртәбә бирелә торган акчалата кызыксындыру түләү;

3) кыйммәтле бүләк белән бүләкләү;

4) мактау грамотасы яисә шәһәр җирлегендә билгеләнгән башка төр бүләкләр белән бүләкләү;

5) законнар нигезендә дәүләт бүләкләре белән бүләкләү;

6) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә шәһәр җирлегенең муниципаль хокукый актларында билгеләнгән башка төрләре.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендәге 1-3 пунктларында каралган кызыксындыруларны куллану тәртибе һәм шартлары Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

85 статья.Муниципаль хезмәткәрнең дисциплинар җаваплылыгы

1. Муниципаль хезмәткәр дисциплинар гамәл кылган – үзенә йөкләнгән хезмәт бурычларын үз гаебе белән үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) түбәндәге дисциплинар җәза чараларын кулланырга хокуклы:

1) кисәтү;

2) шелтә ясау;

3) тиешле нигезләр буенча муниципаль хезмәттән азат итү.

2. Дисциплинар гамәл кылган муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларны үтәүдән, аның дисциплинар җаваплылыгы турындагы мәсьәлә хәл ителгәнче, вакытлыча (әмма бер айдан да озагракка түгел) акчалата хезмәт хакы сакланып, читләштерелергә мөмкин. Бу очракта муниципаль хезмәткәрне вазыйфаи бурычларны үтәүдән читләштерү муниципаль хокукый акт нигезендә башкарыла.

3. Дисциплинар җәза бирүләрне куллану һәм кире алу тәртибе хезмәт законнары белән билгеләнә.

86 статья. Чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җәзалар

1. Муниципаль хезмәткәр чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәгән һәм 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законда, 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы көрәш максатларында куелган бурычларны үтәмәгән өчен әлеге Кодексның 32 статьясында каралган җәзалар билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәр, әлеге Кодексның 17 һәм 18 статьяларында каралган хокук бозуларны кылган очракларда ышаныч югалтуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәттән азат ителергә тиеш.

3. Әлеге Кодексның 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган җавапка тартулар эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә кулланыла:

1) тиешле муниципаль органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе (алга таба – хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе) уздырган тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад;

2) әгәр тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә җибәрелсә, комиссия күрсәтмәсе;

3) муниципаль хезмәткәрнең ризалыгы белән генә һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тануы шарты белән, хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел хокук бозу кылыну хакында аны кылуның факттагы хәлләре бәян ителгән докладывы һәм муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге җәза бирелүдән тыш);

4) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары;

5) башка материаллар.

4. Хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тикшерү уздыру өчен түбәндәгеләр тарафыннан язма рәвештә бирелгән җитәрлек мәгълүмат нигез була:

1) хокук саклау органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

2) сәяси партияләрнең региональ яисә җирле бүлекчәләре, шулай ук закон нигезендә теркәлгән, сәяси партияләр булмаган региональ иҗтимагый берләшмәләр;

3) тиешле муниципаль берәмлектә төзелгән иҗтимагый совет;

4) массакүләм мәгълүмат чаралары.

5. Аноним хәбәрләр хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан тикшерү үткәрү өчен нигез була алмый.

6. Хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе, тикшерү уздырганчы, муниципаль хезмәткәрдән язма рәвештә аңлатма алырга тиеш. Әгәр муниципаль хезмәткәр әлеге аңлатманы ике эш көне эчендә бирмәсә, тиешле акт төзелә. Муниципаль хезмәткәр тарафыннан аңлатма бирелмәү тикшерү уздыруга тоткарлык була алмый.

7. Муниципаль хезмәткәр әлеге Кодексның 17 статьясындагы 5 яисә 7 өлешендә каралган хокук бозуларны кылган очракта, тикшерү нәтиҗәләре турында доклад, муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы һәм башка материаллар хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясенә тапшырыла, ул исә эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) өчен муниципаль хезмәткәргә дисциплинар җәза куллану буенча тәкъдимнәр әзерли.

Муниципаль хезмәткәр башка төрле хокук бозган очракта, тикшерү нәтиҗәләре турында доклад, муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы һәм башка материаллар хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан эшкә яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) тапшырыла.

8. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган җавапка тартуларны кулланганда, муниципаль хезмәткәр кылган коррупциячел хокук бозуның характеры, аның авырлыгы, аны кылгандагы шартлар, муниципаль хезмәткәрнең башка чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмый калу яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәве һәм коррупциягә каршы көрәш максатларында билгеләнгән бурычларны үтәве, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең моңа кадәр үз вазыйфаи бурычларын башкару нәтиҗәләре исәпкә алына.

9. 17, 18 һәм 32 статьяларында каралган җәза бирүләр, муниципаль хезмәткәрнең вакытлыча эшкә сәләтсез булган чорларын, аның чираттагы ялда булуын санамыйча, муниципаль хезмәткәрнең коррупциячел хокук бозу кылуы турында мәгълүмат кергән көннән алып алты айдан да соңга калмыйча һәм аның коррупциячел хокук бозу кылган көненнән алып өч елдан да соңга калмыйча кулланыла. Күрсәтелгән срокларга җинаять эше буенча башкару вакыты керми.

10. Муниципаль хезмәткәр коррупциячел хокук бозган очракта, аны җавапка тарту турындагы актта җавапка тарту өчен нигез буларак 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль законның $27^1$ статьясындагы 1 яисә 2 өлеш күрсәтелә.

11. Хокук бозуны һәм нигезләмәләре бозылган норматив хокукый актлар күрсәтелгән муниципаль хезмәткәргә карата җавапка тарту куллану турындагы яисә муниципаль хезмәткәргә карата мондый җавапка тарту куллванудан нигезләре күрсәтелгән баш тарту турындагы актның күчермәсе тиешле акт чыгарылган көннән алып өч эш көне эчендә муниципаль хезмәткәргә расписка белән тапшырыла. Әгәр муниципаль хезмәткәр күрсәтелгән расписканы бирүдән баш тартса, тиешле акт төзелә.

12. Муниципаль хезмәткәр җавапка тартуга карата федераль закон нигезендә шикаять бирә ала.

13. Әгәр җавапка тарту кулланылган көннән бер ел эчендә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 яисә 2 пунктында каралган дисциплинар җавапка тартуны, ул бирелгән көннән алып бер ел узганчы, үз инициативасы, муниципаль хезмәткәрнең язма гаризасы яисә аның турыдан-туры җитәкчесе үтенече буенча кире алырга хокуклы.

14. Эшкә яллаучы вәкиле (эш бирүче) муниципаль хезмәткәрдән муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 32 статьясындагы 1 өлешенең 1 яисә 2 пунктында каралган дисциплинар җавапка тартуны, ул бирелгән көннән алып бер ел узганчы, үз инициативасы,

муниципаль хезмәткәрнең язма гаризасы яисә аның турыдан-туры җитәкчесе үтенече буенча кире алырга хокуклы.

87 статья. Муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган гарантияләр

1. Муниципаль хезмәткәргә түбәндәгеләр гарантияләнә:

1) вазыйфаи инструкция нигезендә аның вазыйфаи бурычларын үтәвен тәэмин итәрлек эш шартлары;

2) акчалата вазыйфаи тулы керемне вакытында һәм тулы күләмдә алу хокукы;

3) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәре һәм эш көннәре булмаган бәйрәм көннәре, шулай ук еллык түләүле отпуск бирү юлы белән тәэмин ителә торган ял;

4) муниципаль хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына, шул исәптән муниципаль хезмәткәр пенсиягә чykканнан соң да, медицина хезмәте күрсәтү;

5) тиешле еллар эшләгән өчен һәм инвалидлыкка бәйле рәвештә пенсия тәэминаты, шулай ук, муниципаль хезмәткәр вазыйфаи бурычларын үтәгәндә вафат булган очракта, муниципаль хезмәткәрнең гаилә әгъзаларына пенсия тәэминаты;

6) вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрнең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян килү очрагына мәҗбүри дәүләт иминләштерүе;

7) муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узган чорда яисә муниципаль хезмәттән киткәннән соң, әмма вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә авырган яисә хезмәткә сәләтен югалткан очракка мәҗбүри дәүләт социаль иминләштерүе;

8) муниципаль хезмәткәрне һәм аның гаилә әгъзаларын муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә көч кулланулардан, янаулардан һәм хокукка каршы башка гамәлләрдән федераль законнарда билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда яклау.

9) законнарда, шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәдә билгеләнгән очракларда, акчалата түләүне саклап, шәһәр җирлеге бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә һөнәри белем алу;

10) Россия Федерациясе Хезмәт Кодексында, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында, шәһәр җирлегенең муниципаль хокукый актларында каралган гарантияләрдән тыш, пенсиягә чыгу сәбәпле, өстәмә рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү гарантияләнә. Күрсәтелгән гарантиянең шартлары, күләме һәм түләү тәртибе шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәткәргә закон, Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмә нигезендә хезмәт командировкаларына, муниципаль хезмәткә кабул итүгә, муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчүгә, башка җиргә муниципаль хезмәткә җибәрелүгә бәйле чыгымнар һәм башка компенсацияләр бирелә, шулай ук моңа бәйле транспорт чыгымнары һәм торак өчен түләү чыгымнары каплана.

3. Муниципаль хезмәткәргә, аның муниципаль хезмәт үтү шартларына бәйле рәвештә, хезмәт транспорты бирелә яки хезмәт максатларында, Шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәдә билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә шәхси транспортны куллануга бәйле чыгымнар каплана.

4. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе бетүгә йә җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләре штатын кыскартуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсен өзгәндә, муниципаль хезмәткәргә оешма ябылуга йә оешманың хезмәткәрләр штаты кыскартуга бәйле рәвештә эштән җибәрү очрагында хезмәткәрләр өчен хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.

5. Муниципаль хезмәткәрләр өчен гарантияләр бирүгә бәйле чыгымнар, әгәр федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында башкача каралмаган булса, шәһәр җирлеге бюджеты хисабына башкарыла.

88 статья. Муниципаль хезмәткәргә хезмәте өчен түләү

1. Муниципаль хезмәткәргә хезмәте өчен түләү муниципаль хезмәткәрнең үзе биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы нигезендә вазыйфаи оклады (алга таба – вазыйфаи оклад), шулай ук муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы белән билгеләнә торган айлык һәм башка өстәмә түләүләр (алга таба – өстәмә түләүләр) тәшкил итә торган акчалата вазыйфаи тулы керем рәвешендә гамәлгә ашырыла.

2. Вазыйфаи оклад күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә чыгарыла торган шәһәр җирлеге Советы карарлары белән билгеләнә.

89 статья. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру турында белешмәләр тапшыру

1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы граждан, муниципаль хезмәткәр һәркем файдалана алырлык мәгълүматны, шулай ук аларны танырга мөмкинлек бирүче белешмәләрне урнаштырган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтларның һәм (яисә) сайтлар сәхифәләренең адреслары турында белешмәләрне яллаучы вәкиленә түбәндәгеләр тапшыра:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы граждан – хезмәткә кергәндә муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге өч календарь ел өчен;

2) муниципаль хезмәткәр – ел саен күрсәтелгән мәгълүматны тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен, моңа һәркем файдалана алырлык мәгълүматны муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәү кысаларында урнаштыру очраклары керми.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачы гражданнар тарафыннан – муниципаль

хезмәткә кергәндә, ә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән рәвеш буенча тапшырыла.

3. Яллаучы вәкиленең карары буенча ул вәкаләт биргән муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъвачылар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган һәркем файдалана алырлык мәгълүматны эшкәртүне, шулай ук әлеге статьяның 1 өлешендә каралган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне гамәлгә ашыралар.

## XV бүлек. ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНЕҢ ИКЪТИСАДИ НИГЕЗЕ

### 90 статья. Шәһәр җирлегенең икътисади нигезе

Шәһәр җирлегенең икътисади нигезен муниципаль милкентәге мөлкәт, шәһәр җирлеге бюджеты акчалары, шулай ук шәһәр җирлегенең милек хокуклары тәшкил итә.

### 91 статья. Шәһәр җирлегенең муниципаль мөлкәте. Шәһәр җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, файдалану һәм эш итү

Шәһәр җирлеге милкендә булган муниципаль мөлкәт исемлеге 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнә. Шәһәр җирлегенең муниципаль милкенә ия булу, файдалану, эш итү, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, хуҗалык җәмгыятьләре булдыру гамәлдәге законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 92 статья. Шәһәр җирлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары

1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары федераль законнар нигезендә шәһәр җирлеге Советы карарлары белән билгеләнә.
2. Муниципаль мөлкәтне кулланудан һәм хосусыйлаштырудан кергән керемнәр шәһәр җирлеге бюджетына керә.

### 93 статья. Муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре

1. Шәһәр җирлегенең муниципаль берәмлеге гамәлдәге федераль законнар, әлеге Устав һәм башка муниципаль норматив-хокукый актлар белән билгеләнгән үз вәкаләтләре кысаларында, муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне булдырырга, үзгәртеп корырга һәм юкка чыгарырга, хуҗалык җәмгыятьләрен, шул исәптән, җирле әһәмияткә ия

мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен кирәк булган муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен төзүдә катнашырга хокуклы. Муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләргә карата оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен вәкаләтле җирле үзидарә органнары башкара.

2. Җирле үзидарә органнары муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр эшчәнлегенең максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, аларның уставларын раслый, әлеге предприятие һәм учреждение җитәкчеләрен вазыйфага билгели һәм вазыйфадан азат итә, әлеге Уставта каралган тәртиптә эшчәнлек турында хисапларны тыңлый.

3. Шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль казна учреждениеләрнең йөкләмәләре буенча субсидиар рәвештә җавап тоталар һәм федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә аларны тормышка ашыруны тәэмин итәләр.

94 статья. Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара бәйләнеше

Шәһәр җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, шулай ук физик затлар белән үзара бәйләнеше, федераль законда, Татарстан Республикасы законында башкача билгеләнмәгән булса, шартнамә нигезендә төзелә.

## XVI бүлек. ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕНЕҢ ФИНАНС НИГЕЗЕ

95 статья. Шәһәр җирлеге бюджеты

1. Шәһәр җирлегенең үз бюджеты бар.

2. Шәһәр җирлеге бюджеты шәһәр җирлеге Советының муниципаль хокукый акты рәвешендә эшләнә һәм раслана.

3. Шәһәр җирлеге бюджетында шәһәр җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган керемнәр һәм шәһәр җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен бирелә торган субвенцияләр, шулай ук күрсәтелгән керемнәр һәм субвенцияләр исәбеннән шәһәр җирлеге бюджетының тиешле чыгымнары аерым карала.

4. Җирлек җирле үзидарә органнары федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителүче Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә федераль дәүләт хакимияте органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына җирлек бюджеты үтәлеше турында хисаплар тапшыралар.

96 статья. Шәһәр җирлегендә бюджет процессы

1. Шәһәр җирлеге бюджетын формалаштыру, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла. Шәһәр җирлеге бюджетын формалаштыру, раслау һәм үтәү тәртибе Россия Федерациясе Бюджет кодексы, федераль законнар белән билгеләнә.

2. Шәһәр җирлеге бюджеты проекты, шәһәр җирлеге бюджетын раслау турындагы шәһәр җирлеге Советы карары, аның үтәлеше турындагы еллык хисап, шәһәр җирлеге бюджеты үтәлү барышы һәм җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең һәм муниципаль учреждениеләрдәге хезмәткәрләр саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә киткән факттагы чыгымнар турында һәр квартал саен бирелә торган белешмәләр рәсми рәвештә бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

3. Җирле салымнар турында муниципаль хокукый актларга үзгәрешләр кертү хакында шәһәр җирлеге Советының муниципаль хокукый актлары, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен үзгәртүгә китерә торган, чираттагы финанс елында һәм планнар чорында үз көченә керә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы шәһәр җирлеге Советының муниципаль хокукый актлары чираттагы финанс елына һәм планнар чорына җирлек бюджеты турында карар проекты шәһәр җирлеге Советына кертелгән көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

4. Шәһәр җирлеге бюджеты проекты өч елга (чираттагы финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлеге бюджеты проекты, шәһәр җирлегенең чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү максатларында, шәһәр җирлегенең социаль-икътисадый үсешен фаразлау нигезендә төзелә.

6. Чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлеге бюджеты проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның таләпләрен үтәп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Устав нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда төзелә.

7. Чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлеге бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

1) Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләренә;

2) Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасына;

3) шәһәр җирлегенең бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм шәһәр җирлегенең салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;

4) шәһәр җирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразларына;

5) озак сроклы чорга шәһәр җирлегенең бюджет фаразына (бюджет фаразы проектына, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проектына);

6) шәһәр җирлегенең муниципаль программаларына (муниципаль

программалар проектларына, күрсәтелгән программаларны үзгәртү проектларына).

8. Чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карарда бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты (дефициты) кергән төп характеристикалары булырга тиеш.

9. Чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карарда, әгәр Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнмәгән булсалар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативлары, шулай ук керемнәр төренең төркемнәре, төркемчәләре һәм статьялары буенча шәһәр җирлеге бюджеты керемнәренең фаразланган күләмнәре булырга тиеш.

10. Шәһәр җирлеге бюджеты турында карар белән түбәндәгеләр билгеләнә:

шәһәр җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге;

шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;

чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасында бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү;

гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

чираттагы финанс елында һәм план чорында башка бюджетлардан алына торган һәм яисә Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

план чорының беренче елына шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме шәһәр бюджеты чыгымнары (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар исәбеннән каралган шәһәр бюджеты чыгымнарын исәпкә алмыйча) гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә, план чорының икенче елына – шәһәр бюджеты чыгымнары гомуми күләменең кимендә 5 проценты күләмендә;

чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96 статьясында билгеләнгән шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары;

чираттагы финанс елыннан соң һәм һәр план чоры елыннан соң килә торган елның беренче гыйнварына муниципальның эчке бурычының иң югары чиге һәм (яисә) муниципальның тышкы бурычының иң югары чиге, шул исәптән муниципальның дәүләт гарантияләре буенча бурычының иң югары чиге;

шәһәр җирлеге бюджетының Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексында шәһәр җирлеге Советының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән башка күрсәткечләр.

11. Чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет расланган очракта, шәһәр җирлеге бюджеты турында карар проекты расланган бюджетның план чорының параметрларын үзгәртү һәм аларга бюджет проектының план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән раслана.

Шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы күрсәткечләрен үзгәртү расланган бюджет ассигнованиеләрен арттыру яисә кыскарту йә шәһәр җирлеге бюджетының өстәмә максатчан статьялары һәм (яисә) чыгымнары төрләре буенча бюджет ассигнованиеләре чыгымнарын ведомство структурасына кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

12. Чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта шәһәр җирлеге Советына түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлегенең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

шәһәр җирлеге бюджетының керем чыганаклары реестры;

агымдагы финанс елының узган чорында шәһәр җирлегенең социаль-икътисадый үсешенең якынча йомгаклары һәм агымдагы финанс елында шәһәр җирлегенең социаль-икътисадый үсешенең көтелә торган йомгаклары;

чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлегенең социаль-икътисадый үсеш фаразы;

чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлегенең берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет кытлыгы) фаразы;

шәһәр җирлеге бюджеты проектына аңлатма язуы;

бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикаларның проектлары) һәм исәп-хисаплары;

- чираттагы финанс елыннан  һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның (чираттагы финанс елыннан соң) 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычының иң югары чиге;

агымдагы финанс елына бюджетның көтелә торган үтәлешен бәяләү;

шәһәр җирлеге Советы, шәһәр җирлегенең Ревизия комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата район Башкарма комитеты белән каршылыклар килеп чыккан очракта тапшырыла;

Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм әлеге Уставта билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

13. Шәһәр җирлеге бюджеты проектын төзү һәм район Башкарма комитетының аерым прерогативасы. Бюджет проектларын турыдан-туры Зеленодольск муниципаль районының финанс органы гамәлгә ашыра.

14. Район Башкарма комитеты шәһәр җирлеге советына чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карар проектын агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча кертә.

15. Шәһәр җирлеге бюджеты турында карар проектын карау һәм шәһәр җирлеге Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән раслау

тәртибе, чираттагы финанс елының 1 гыйнварыннан бюджет турындагы карарның үз көченә керүен, шулай ук күрсәтелгән карар белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясы нигезендә күрсәткечләрне һәм характеристикаларны раслауны күздә тотарга тиеш.

16. Шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карар, финанс елының 1 гыйнварыннан үз көченә керә һәм 31 декабренә кадәр гамәлдә була, әгәр Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм (яисә) шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карарда башкасы каралмаган булса.

Шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карар, аңа кул куелганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча, билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

17. Җирле үзидарә органнары шәһәр җирлеге бюджетының балансын һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу, бюджет процессын гамәлгә ашыру, кытлык күләме, муниципаль бурыч күләме һәм структурасы, җирлекнең бюджет йөкләмәләрен үтәү буенча билгеләнгән федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын үтәүне тәэмин итәләр.

18. Шәһәр җирлеге бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә формалаша.

19. Шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнары Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

20. Федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслауга шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, рөхсәт ителми.

21. Муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә гамәлгә ашырыла.

97 статья. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

98 статья. Шәһәр җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы

1. Гражданнарның үзара салым акчасы ул- гражданнар тарафыннан җирле әһәмияткә ия конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен бер тапкыр башкарылучы түләүләр. Үзара салым түләү күләме шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең барысы өчен дә абсолют күләмдә тигез итеп билгеләнә, шәһәр җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 проценттан да артмаган өлешен тәшкил иткән һәм алар өчен түләү күләмен киметергә мөмкин булган аерым категория гражданнардан тыш.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бер тапкыр түләүләрне кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясындагы 1 өлешенең 4 һәм 4.1 пунктларында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.

99 статья. Инициативалы проектларны тормышка ашыруны финанс һәм башка яктан тәэмин итү

1. Әлеге Уставта каралган инициатив проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү чыганагы - шәһәр җирлегенең тиешле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы бюджетыннан инициатив түләүләр һәм (яисә) бюджетара трансфертлар күләмнәрен исәпкә алып төзелә торган инициатив проектларны гамәлгә ашыруга шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карар белән каралган бюджет ассигнованиеләре.

2. Инициативалы түләүләр астында гражданнарның, шәхси эшкуарларның һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юридик затларның ирекле нигездә түләнә торган һәм конкрет инициативалы проектларны гамәлгә ашыру максатларында Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә җирле бюджетка күчерелә торган акчалары аңлашыла.

3. Әгәр дә инициатив проект гамәлгә ашырылмаган булса, инициативалы түләүләр аларны шәһәр җирлеге бюджетына күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиеш. Инициативалы проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча инициативалы проектны гамәлгә ашыру максатларында файдаланылмый торган инициативалы түләүләр калган очракта, әлеге түләүләр шәһәр җирлеге бюджетына күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиеш.

Аларны шәһәр җирлеге бюджетына күчерүне гамәлгә ашыручы затларга (шул исәптән оешмаларга) кире кайтарылырга тиешле инициативалы түләүләр суммаларын исәпләү һәм кире кайтару тәртибе шәһәр җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

4. Инициативалы проектларны тормышка ашыру, шулай ук, кызыксынган затларның ирекле мөлкәти һәм (яки) хезмәттә катнашуы рәвешендә дә тәэминителергә мөмкин.

100 статья. Шәһәр җирлегенең муниципаль бурыч алулары (муниципаль бурыч)

1. Шәһәр җирлеге, шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау һәм бурыч йөкләмәләрен түләү максатларында, муниципаль эчке бурыч алулар башкарырга хокуклы.

2. Муниципаль бурыч алуларны шәһәр җирлеге исеменнән гамәлгә ашыру хокукы Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә район

Башкарма комитетына (Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма-боеру органы вәкаләтләрен башкарганда) ия.

3. Агымдагы финанс елы башына шәһәр җирлеге бюджеты акчаларының калган өлешләре агымдагы финанс елында шәһәр җирлеге бюджеты турындагы карар белән шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслауның күрсәтелгән чыганагы буларак каралган акчалар күләменнән артып киткән күләмдә касса өзеклекләрен каплауга юнәлдерелергә мөмкин.

101 статья. Бюджет хисабы. Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында еллык хисап

1. Шәһәр җирлегенең бюджет хисаплылыгы еллык хисап булып тора.

2. Шәһәр җирлегенең бюджет хисаплылыгы район Башкарма комитеты тарафыннан бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисаплылыгы нигезендә төзелә.

3. Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап шәһәр җирлеге Советы карары белән расланырга тиеш.

4. Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап шәһәр җирлеге Советына тәкъдим иткәнчегә кадәр тышкы тикшерелергә тиеш, ул бюджет акчаларының баш администраторларының бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерүне һәм шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала.

Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү, әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләрен үтәп, шәһәр җирлегенең Ревизия комиссиясе тарафыннан башкарыла.

5. Район Башкарма комитеты, аңа бәяләмә әзерләү өчен, агымдагы финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча, шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап бирә. Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү 1 айдан да артмаган срокта, бюджет акчаларының баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерү күрсәткечләре нигезендә башкарыла.

6. Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә шәһәр җирлегенең Ревизия комиссиясе тарафыннан шәһәр җирлеге Советына бер үк вакытта район Башкарма комитетына җибәрелә.

7. Ел саен, агымдагы финанс елының 1 маеннан да соңга калмыйча, район Башкарма комитеты шәһәр җирлеге Советына хисап финанс елы өчен шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны, хисап финанс елы өчен шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында шәһәр җирлеге Советы карары проектын, шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында башка бюджет хисаплылыгын һәм Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документларны тәкъдим итә.

9. Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча шәһәр җирлеге Советы шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

Шәһәр җирлеге Советы тарафыннан шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап кире кагылган очракта, ул мәгълүматларны дөрес булмаган яки тулы булмаган чагылдыру фактларын бетерү һәм 1 айдан артмаган срокта кабат тапшыру өчен кире кайтарыла.

10. Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы карар белән, шәһәр җирлеге бюджеты керемнәренең, чыгымнарының һәм кытлыкның гомуми суммасы күрсәтелеп, хисап финанс елы өчен шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап раслана.

Хисап финанс елында шәһәр җирлеге бюджеты үтәлеше турында шәһәр җирлеге Советы карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

бюджетлар керемнәрен классификацияләү кодлары буенча шәһәр җирлеге бюджеты керемнәре;

керемнәр төрләре, керемнәр төрләре кодлары, дәүләт идарәсе секторы операцияләре классификацияләре кодлары буенча шәһәр җирлеге бюджеты керемнәре ;

шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнары;

бюджетлар чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча шәһәр җирлеге бюджеты чыгымнары;

бюджетлар кытлыгын финанслау чыганакларының классификациясе кодлары буенча шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары;

шәһәр җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары төркемнәре, төркемчәләре, статьялары, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары кодлары буенча дәүләт идарәсе секторы операцияләрен классификацияләү

102 статья. Шәһәр җирлегенең җирле бюджеты үтәлеше

1. Шәһәр җирлегенең җирле бюджетын үтәү Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә башкарыла.

2. Шәһәр җирлеге бюджеты кассаның бердәмлеге һәм чыгымнарның ведомство буйсынуы нигезендә башкарыла.

3. Шәһәр җирлеге бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү, шәһәр җирлеге бюджеты акчаларын алучыларның шәхси счетларын ачу һәм алып бару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

4. Шәһәр җирлеге бюджетын үтәү шәһәр җирлегенең җыелма бюджет язмасы һәм шәһәр җирлегенең касса планы нигезендә оештырыла.

103 статья. Муниципаль финанс контроле

1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актларның, Зеленодольск шәһәре бюджетыннан физик затларга гавами норматив йөкләмәләрне һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләрне тәэмин итә торган хокукый актларның нигезләмәләрен үтәүне

тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла, шулай ук бюджеттан акчалар бирү турында муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәү.

Муниципаль финанс контроле тышкы һәм эчке, башлангыч һәм соңгыга бүленә.

2. Тышкы муниципаль финанс контроле Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.

3. Эчке муниципаль финанс контроле районның Финанс-бюджет палатасының контроль эшчәнлеге булып тора (алга таба - эчке муниципаль финанс контроле органнары).

4. Башлангыч контроль шәһәр җирлегенең җирле бюджетын үтәү барышында бюджет бозуларны кисәтү һәм булдырмау максатларында башкарыла.

5. Соңгы контроль аларны үтәү законлылыгын, исәпкә алу һәм хисаплылыкның дөреслеген билгеләү максатларында, шәһәр җирлеге бюджетын үтәү нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

## XVII бүлек. ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫН КАБУЛ ИТҮ. ӘЛЕГЕ УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ

### 104 статья. Шәһәр җирлеге Уставы проектын әзерләү, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

1. Шәһәр җирлеге Уставы проекты, шәһәр җирлеге Советы карары проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында шәһәр җирлеге Советына шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Советы депутатлары, район Башкарма комитеты җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициативалы төркемнәре тарафыннан кертелә ала.

2. Шәһәр җирлеге Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен шәһәр җирлеге Советы карары белән махсус комиссия төзелергә мөмкин. Әлеге комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре, экспертлар чакырыла ала.

3. Шәһәр җирлеге Уставы проекты, шәһәр җирлеге Советының Шәһәр җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты шәһәр җирлеге советы тарафыннан шәһәр җирлеге Уставын кабул итү, шәһәр җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәсьәләне карау көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, шәһәр җирлеге Советы тарафыннан билгеләнгән Устав проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибенең, күрсәтелгән муниципаль хокукый актның проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибенең, шулай ук гражданнарның аның турында фикер алышуда катнашу тәртибенең бер үк вакытта рәсми рәвештә басылып чыгуы (халыкка җиткерелүе) белән рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Шәһәр җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм

өстәмәләр кертү турында шәһәр җирлеге Советы карары проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук шәһәр җирлеге Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен шәһәр җирлеге Уставын әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелгән очракта, гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

4. Шәһәр җирлеге Уставы проекты, әлеге Уставка шәһәр җирлеге Советының үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проекты буенча, аларны шәһәр җирлеге Советы утырышында карау алдыннан, шәһәр җирлеге Уставын Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе яки Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау формасында, әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатында Уставка үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш, әлеге Устав нигезендә гавами тыңлаулар үткәрелә.

5. Шәһәр җирлеге Уставын яңа редакциядә шәһәр җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт белән бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта шәһәр җирлегенең яңа Уставы кабул ителә, ә элеккеге муниципаль берәмлекнең гамәлдәге Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актлар, шәһәр җирлегенең яңа Уставы үз көченә кергән көннән, үз көчләрен югалткан дип таныла.

105 статья. Шәһәр җирлеге Уставын кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

1. Шәһәр җирлеге Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проектын карау шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кимендә ике укылышта, шәһәр җирлеге Советы Регламенты нигезендә башкарыла.

2. Шәһәр җирлеге Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын беренче укылышта кабул иткәннән соң әлеге проект шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан әлеге Уставның 70 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән шәһәр җирлеге Советы депутатларына, хокукый акт чыгару инициативасы хокукына ия башка субъектларга төзәтмәләр кертү өчен җибәрелә.

3 Шәһәр җирлеге Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карары күпчелек тавыш белән, билгеләнгән сандагы шәһәр җирлеге Советы депутатларының өчтән ике өлеше тавыш биргәндә, кабул ителә. Шәһәр җирлеге Башлыгының тавышы, шәһәр җирлеге Уставын, шәһәр җирлеге Советының шәһәр җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарын кабул иткәндә, шәһәр җирлеге Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.

106 статья. Шәһәр җирлеге Уставының үз көченә керү тәртибе, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар

1. Шәһәр җирлеге Уставы, шәһәр җирлеге Советының әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары кабул ителгәннән соң, шәһәр җирлеге Башлыгы тарафыннан башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органының муниципаль берәмлекләрнең уставларын теркәү өлкәсендәге территориаль органына, федераль законда билгеләнгән тәртиптә, дәүләт теркәве уздыру өчен җибәрелә.

2. Шәһәр җирлеге Уставы, шәһәр җирлеге Советының әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карары дәүләт теркәвенә алынганнан соң рәсми рәвештә бастырылып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), «Зеленодольская правда» газетасында хокукый акт текстын рәсми рәвештә бастырып чыгарылганнан (халыкка җиткерелелгәннән) соң үз көченә керә. Шәһәр җирлеге Уставын, шәһәр җирлеге Советының әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карарын дәүләт теркәвенә алганнан соң, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталында (http://pravo-minjust.ru, http://хокук-минюст.рф) график сурәтләр рәвешендә муниципаль берәмлекләр уставларының дәүләт реестрына кертелергә тиеш.

Шәһәр җирлеге Башлыгы шәһәр җирлегенең теркәлгән Уставын, шәһәр җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны муниципаль берәмлекләр Уставларын теркәү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан кергән көннән алып җиде көн эчендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) бурычлы.

Шәһәр җирлеге Уставына кертелгән һәм җирле үзидарә органнарының структурасын үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне бүлү (шәһәр җирлеге Уставын федераль законнарга туры китерү, шулай ук җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлау вәкаләтләре, вәкаләтләре чоры, тәртибе үзгәрү очрагыннан тыш) шәһәр җирлеге Уставына күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актны кабул иткән шәһәр җирлеге Советының вәкаләтләре вакыты чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт белә кертелә, ул түбәндәгечә рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) шәһәр җирлеге Советы карары белән, шәһәр җирлеге Башлыгы, шәһәр җирлеге Советы рәисе вәкаләтләрен башкаручы белән;

2) шәһәр җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән һәм шәһәр җирлеге Башлыгы имзалаган аерым норматив хокукый акт белән. Бу очракта аны кабул итү турында әлеге хокукый актта шәһәр җирлеге Советы карары

реквизитлары куела. Шәһәр җирлеге Советының мондый карарына шәһәр җирлеге Уставына кертелә торган үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турында күчеш нигезләмәләрен һәм (яисә) нормаларын кертү рөхсәт ителми.